ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

## № 9

сентябрь
1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
1999

# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 9*
*сентябрь*
*1999*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
1999

Лицензия № 174 1996 елның 03.10 бирелде
Җитештерүгә тапшырылды
Формат А5. Оригинал-макеттан басылды
Тиражы 1000 нөсхә. Заказы 3785
Бәясе килешү буенча.
"АБАК" нәшрияты.
420045 Казан, Н.Ершов ур., 31б.
Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять АБАК-хөзмәт күрсәтү үзәгендә басылды
Лицензия № 0080 1997 елның 03.12 бирелде
420107 Казан, Һади Такташ ур., 105

*ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696*
**Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы:**
© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Эчтәлек

# I

668. Татарстан Республикасының Су кодексы ........................................ 7

669.«Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле рәвештә «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 55

670.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясенең көн тәртибе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 56

671.«Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны билгеләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 58

672.«Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе составын раслау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ... 58

673.«Россия Федерациясе Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча округ сайлау комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 60

674.«Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны туктатып тору турында»*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 62

675.«Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты - Татарстан Республикасы Хөкүмәте структурасына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .............. 63

676.«З.Р.Вәлиева кандидатурасын Татарстан Республикасының матбугат, телерадиотап-шырулар эшләре һәм массакүләм коммуникация чаралары министры урынына килештерү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 65

677.«Татарстан Республикасы халык депутаты З.Р.Вәлиева турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 66

678.«Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте вәкиллекле органнары һәм дәүләт идарәсе органнары хезмәткәрләренең хезмәт хаклары күләмнәрен арттыру турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................ 66

679.«Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы

законы проектын эшләүне дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................ 67

680.«Татарстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................ 68

681.«Татарстан Республикасы халык депутаты А.Є.Камаловны Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими нигездә эшләүдән азат итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................ 68

682.«Татарстан Республикасы халык депутаты И.Г.Хөснетдиновның «Татарстан Республикасы югары уку йортларын финанслау турында» таләбе хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .... 69

683.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 23 сентябрендәге утырышы көн тәртибе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................ 69

684.«Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны туктатып тору турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 15 сентябрендәге карарын үтәүнең барышы хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................ 71

685.«Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм рәисләрен раслау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................ 72

686.«Татарстан Республикасы халык депутатларының район, шәһәр Советлары халык депутатларының санлы составы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................ 73

687.«Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча 23 нче Мәскәү сайлау округының округ сайлау комиссиясе составындагы үзгәреш турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................ 75

688.«Татарстан Республикасы гражданнарының хокук тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында» ........................................................ 76

689.«Наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше һәм аларны куллану белән бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................................................ 76

690.«Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы

законы проектын эшләүне дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 77

691.«Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 78

692.«Авыл хуҗалыгы җирләре залогы турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 78

693.«Халыкны туберкулездан саклау һәм туберкулезга каршы ярдәм турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 79

**II**

694.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 80

695.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясе каравына кертелүче мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 81

696.«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы көзге сессиясе чакыру турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 82

697.«1999 елның 23 сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 82

698.«1999 елның 23 сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 83

699.«Суд участоклары һәм мировой судьялар урыннары турында» Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау нәтиҗәләре хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 84

700.«Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.С.Шәйдуллинның закон чыгару тәкъдиме турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 84

701.«Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 85

702.«Татарстан Республикасында риэлтерлык эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында»*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............................ 85

703.«Татарстан Республикасы прокуратурасы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* .................................................... 86

## III

704. «Татарстан Республикасы Иминлек советы төзү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы*.........................................................87

705.«Кадрлар мәсьәләләре буенча җирле хакимият һәм республика дәүләт идарәсе органнарының эшчәнлеген җайга салу хакында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................... 89

706.«Татар аграр-сәнагать банкын булдыру хакында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ................................................. 90

707.«Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына түләүләрнең керүен тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...................................... 91

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## 668. Татарстан Республикасының Су кодексы

Сулар әйләнә-тирә табигать мохитенең иң мөһим компоненты, алар Татарстан Республикасы халкының байлыгы буларак кулланылалар һәм сакла765налар, халыкның икътисадый, социаль һәм экологик иминлеген, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының тереклеген, республиканың хуҗалык мөстәкыйльлеген тәэмин итәләр.

### I Бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. **Төп төшенчәләр**

Әлеге Кодекста түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

сулар - су объектларындагы барлык су;

су ресурслары - су объектларында урнашкан һәм кулланыла торган яисә кулланылуы мөмкин булган җир өсте һәм җир асты суларының запаслары;

су объекты - коры җир өстендә аның рельефы рәвешләрендә яисә җир астында су режимы рәвешендә күләме һәм чикләре булган суларның җыелып торуы;

су режимы - су объектларында сулар дәрәҗәсенең, чыгымнарының һәм күләмнәренең вакыт аралыгында үзгәреп торуы;

җир өсте сулары - даими рәвештә яисә вакытлыча өске су объектларында урнашкан сулар;

җир өсте су объектлары - коры җир өстендә аның рельефы рәвешләрендә, су режимы рәвешендә күләме һәм чикләре булган килеш, суларның даими яисә вакытлыча җыелып торуы;

җир асты сулары - җир асты су объектларында урнашкан сулар, шул исәптән шифалы сулар;

җир асты су объектлары - тау токымнарында, су режимы рәвешендә күләме һәм чикләре булган килеш, гидравлик бәйләнештә торучы суларның җыелып торуы;

су фонды - Татарстан Республикасының дәүләт су кадастрына кертелгән яисә кертелергә тиешле һәм Татарстан Республикасы территориясе чикләрендәге су объектларының бергәлеге;

җир өсте агым суы - сулары өзлексез хәрәкәт итеп торучы өске су объекты (елгалар һәм алардагы сусаклагычлар, инешләр, су ресурсларын бүлешүнең һәм комплекслы файдалануның бассейнара каналлары);

жир өсте сулыклары- табигый яисә ясалма чокырларда сулары әкрен алмашучы суларның бер урынга җыелып торуы рәвешендәге җир өсте су объекты (күлләр, сусаклагычлар, сазлыклар һәм буалар);

аерымланган су объекты (йомык сулык) - башка җир өсте су объектлары белән гидравлик бәйләнеше булмаган кечкенә мәйданлы һәм акмый торган ясалма сулык;

су җыйгыч мәйдан - сулары җыелып, су объектын барлыкка китерә торган территория;

җир өсте су объектының бассейны (алга таба - су объекты бассейны) - гидравлик бәйләнешләре булган сулыкларның һәм агым суларның төп чыганагы диңгезгә яисә күлгә коя торган су җыйгыч мәйданнары территориясе;

акватория - табигый, ясалма яисә шартлы чикләре булган су киңлекләре;

дренаж сулар - дренаж корылмалары белән җыелып, су объектларына агызыла торган су;

җыелма сулар - кулланылганнан соң билгеләнгән тәртиптә су объектларына агызып чыгарылучы яисә пычрак территориядән агып килгән су;

су объектларын куллану - үзләренең матди һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен физик һәм юридик затларның су объектларыннан төрле юллар белән файда күрүе;

су объектларыннан файдалану (судан файдалану) - физик һәм юридик затларның су объектларын куллануга бәйле юридик нигезләнгән эшчәнлекләре;

су объектларын саклау - суларның пычрануын, чүпләнүен, бетәшүен булдырмауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән эшчәнлек;

су объектларын пычрату - җир өсте һәм җир асты суларының сыйфатын начарайтучы, су объектларыннан файдалануны чикләүче йә аларның төпләренә һәм ярларына тискәре йогынты ясаучы зарарлы матдәләрне су объектларына агызу яисә аларны башка ысул белән агызып төшерү, шулай ук барлыкка китерү;

су объектларын чүпләү - су объектларының торышын начарайтучы һәм алардан файдалануны кыенлаштыручы предметларны яисә кисәкчеләрне су объектларына агызу яисә башка ысул белән агызып төшерү;

суларның бетәшүе - җир өсте һәм җир асты су запасларының даими кимүе һәм сыйфатлары начараю;

суларның зарарлы йогынтысы - ярлардан, плотиналардан, дамбалардан һәм башка корылмалардан ташу сулары нәтиҗәсендә суларның ташып чыгуы, аларны вакытлыча су басу, аларның җир астыннан бәреп чыккан сулар астында калуы, җимерелүе, җирләрнең сазлыкка әверелүе һәм тозлануы, туфракның

эрозияләнүе, бозлыклар шуышу һәм аерым территориягә һәм объектларга җир өсте һәм җир асты суларының башка төрле зарарлы йогынтысы;

судан файдаланучы - су объектларыннан файдалану хокукы бирелгән физик яисә юридик зат;

су кулланучы - судан файдаланучыдан үз ихтыяҗларын тәэмин итү өчен билгеләнгән тәртиптә су алучы физик яисә юридик зат;

су хуҗалыгы объекты - су объектларын куллануга, торгызуга һәм саклауга бәйле корылма;

су җыю - су объектларыннан су алу өчен кулланылучы корылмалар һәм җайланмалар комплексы;

су хуҗалыгы эшчәнлеге - физик һәм юридик затларның су объектларын куллануга һәм аларны саклауга бәйле эшчәнлеге;

судан файдалану лицензиясе - җир өсте су объектыннан яисә аның бер өлешеннән файдалану өчен су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан бирелүче махсус рөхсәт, ул су турындагы законнар нигезендә су объектларыннан файдалану хокуклары барлыкка килү нигезләренең берсе булып таныла һәм аңа ия булучының җир өсте су объектыннан яисә аның бер өлешеннән билгеле бер шартларда файдалану хокукын таныклый;

яр буе яклау полосасы - су саклау зонасы чикләрендә махсус саклау режимы булган территория;

су саклау зонасы - чикләнгән хуҗалык эшчәнлеге объекты булган су объекты акваториясе янәшәсендә су объектының пычрануын булдырмый кала торган территория;

бечевник - гомуми кулланылыш су объектлары яр буйларындагы коры җир полосасы.

**2 статья. Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасында су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу әлеге Кодекс һәм аның нигезендә кабул ителүче башка законнар һәм норматив-хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.

**3 статья. Су турындагы законнарның бурычлары**

Су турындагы законнарның бурычлары түбәндәгеләр була:

гражданнарның чиста суга һәм уңай су тирәлегенә хокукларын тәэмин итү;

судан файдалануның оптималь шартларын булдырып тору;

җир өсте һәм җир асты суларының сыйфатын санитар һәм экологик таләпләргә җавап бирерлек хәлдә тотуны тәэмин итү;

су объектларын пычранудан, чүпләнүдән һәм бетәшүдән саклау;

суларның зарарлы йогынтысын булдырмый калу яисә бетерү;
су экосистемаларының биологик төрлелеген саклап калу.

**4 статья. Су турындагы законнар белән җайга салынучы мөнәсәбәтләр**

Су турындагы законнар су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне (су мөнәсәбәтләрен) җайга салалар.

Әйләнә-тирәдә урнашкан һәм су объектларында тупланмаган сулар буенча мөнәсәбәтләр су турындагы законнар белән җайга салу предметына керми. Су объектларыннан алынган суны файдалануга бәйле мөнәсәбәтләр граждан, санитария законнары һәм башка законнар белән җайга салыналар.

Су объектларыннан файдаланганда һәм аларны саклаганда җирләрдән, урманнардан, җир асты байлыкларыннан, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясыннан, атмосфера һавасыннан файдалану өлкәсендә барлыкка килүче мөнәсәбәтләр су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өчен күпме кирәк булса, шул дәрәҗәдә су турындагы законнар белән җайга салыналар.

Җир асты суларын геологик өйрәнү, разведкалау һәм саклау өлкәсендә барлыкка килүче мөнәсәбәтләр җир асты байлыклары турындагы һәм су турындагы законнар белән җайга салыналар.

Су объектларыннан файдаланганда һәм аларны саклаганда барлыкка килүче мөлкәти мөнәсәбәтләр, әлеге Кодекста башкасы каралмаган булса, граждан законнары белән җайга салыналар.

Су объектларыннан файдаланганда һәм аларны саклаганда барлыкка килүче финанс мөнәсәбәтләре, салым мөнәсәбәтләрен дә кертеп, шулай ук башка административ мөнәсәбәтләр финанс турындагы һәм административ законнарның гомуми нигезләмәләре нигезендә су турындагы законнар белән җайга салыналар.

**5 статья. Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә килешүләр**

Акваторияләре һәм бассейннары Татарстан Республикасы территориясендә һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә урнашкан су объектларыннан комплекслы файдалануга һәм аларны саклауга юнәлдерелгән эшчәнлекне җайга салу һәм берләштерү максатларында башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органнары һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары белән су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты яисә аның кушуы буенча су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы бассейн килешүләре һәм башка килешүләр төзи.

Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге үз вәкаләтләренең бер өлешен хөкүмәтара килешүләр нигезендә башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органнарына тапшырырга, шулай ук су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органнары вәкаләтләренең бер өлешен башкарырга хокуклы.

## II Бүлек. Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының компетенциясе

### 6 статья. Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы компетенциясе

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләү;

су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсен законнар белән җайга салу;

су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә мөһим республика программаларын раслау;

су турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору.

### 7 статья. Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты компетенциясе

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә республиканың мөһим программаларын әзерләү һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раславына тәкъдим итү;

су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә республика программаларын эшләүне һәм раслауны оештыру;

сусаклагычларны тотыру һәм эшләтү, республика милкендәге су объектларындагы су ташуларны үткәреп җибәрү режимнарын билгеләү;

республика милкендәге су объектларыннан файдалануны чикләү, туктатып тору һәм тыю турында карарлар кабул итү;

эчәр сулар белән тәэмин итү чыганакларын резервлау;

табигый дәвалау ресурслары булган су объектларыннан аерым очракларда гына эчәр сулар белән тәэмин итү өчен һәм башка максатлар өчен файдалануны рөхсәт итү;

аз сыйдырышлы йөзү чараларында йөзү өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен раслау;

суда кешеләр гомерен саклау кагыйдәләрен раслау;

ташу суларына каршы гамәлләрне әзерләү һәм башкару, Татарстан Республикасы территориясендәге суларның зарарлы йогынтысы нәтиҗәләрен булдырмый калу һәм юкка чыгару;

акваторияләре һәм бассейннары Татарстан Республикасы территориясендә һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә урнашкан су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә бассейн килешүләре һәм башка төрле килешүләр әзерләгәндә, төзегәндә һәм гамәлгә ашырганда катнашу;

су объектларында су саклау зоналарын һәм яр буе яклау полосаларын билгеләү;

республика милкендәге махсус сакланылучы су объектларының, шул исәптән эчәр сулар белән тәэмин итү чыганакларының, аларның зоналарының һәм санитар саклау округларының режимын билгеләү;

су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә законнарда каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

**8 статья. Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы компетенциясе**

Татарстан Республикасының су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан вәкаләт тапшырылган дәүләт идарәсенең республика органы су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы була.

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

су объектларыннан нәтиҗәле файдалануны планлаштыру, су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау буенча дәүләт программаларын әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

судан файдалану (су куллану һәм су бүлеп бирү) лимитларын билгеләү;

җир өсте һәм җир асты суларын дәүләт исәбенә алу;

Татарстан Республикасының су объектлары дәүләт мониторингын һәм дәүләт су кадастрын алып бару;

су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә лицензияләүне тормышка ашыру;

су объектлары торышына йогынты ясый торган хуҗалык объектларын һәм башка объектларны төзү һәм реконструкцияләү өчен проектлау алды һәм проектлау документларына дәүләт экспертизасы уздыруны гамәлгә ашыру;

су объектларыннан файдалануны һәм аларны саклауны һәм аларның су саклау зоналары территорияләреннән файдалану режимын үтәүне дәүләт тарафыннан тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

суларның зарарлы йогынтысын булдырмый калу һәм нәтиҗәләрен бетерү гамәлләрен әзерләү;

законнарда каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

9 статья. **Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары компетенциясе**

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә халык депутатларының җирле Советлары компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

су турындагы законнарның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

су объектларын пычранудан, чүпләнүдән, бетәшүдән саклауга һәм суларның зарарлы йогынтысыннан саклауга юнәлдерелгән программаларны карау һәм раслау;

Татарстан Республикасы законнарында су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсенә караган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә район, шәһәр, шәһәрдәге район җирле администрацияләре компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

коммуналь милектәге аерымланган су объектларына халык депутатларының тиешле Советы билгеләгән тәртиптә идарә итү һәм алар белән эш итү;

су объектларын саклау гамәлләрен планлаштыруны, финанслауны матди-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыру;

тиешле территориядә яшәүче халыкны эчәр сулар һәм хуҗалык көнкүреш сулары белән тәэмин итүне оештыру, шулай ук янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;

су объектларыннан файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан тикшереп тору;

Татарстан Республикасы законнарында су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсенә караган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

**10 статья. Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә җирле үзидарә органнары компетенциясе**

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә җирле үзидарә органнары компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

җирле үзидарә милкендәге аерымланган су объектларын биләү, алардан файдалану һәм алар белән эш итү;

җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен билгеләнгән су объектларыннан файдалануны җайга салу;

җирле үзидарә территориясендә яшәүче халыкны эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итүне оештыру;

җирле үзидарә территориясендә судан гомуми файдалануны җайга салуда катнашу;

су объектларының торышын үз вәкаләтләре чикләрендә тикшереп торуны гамәлгә ашыру.

Җирле үзидарә органнарына су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә законнар нигезендә дәүләтнең кайбер вәкаләтләре һәм күрсәтелгән вәкаләтләрне башкару өчен кирәкле матди һәм финанс чаралары тапшырылырга мөмкин. Тапшырылган вәкаләтләрнең гамәлгә ашырылышын дәүләт тикшереп тора.

## III бүлек. Су мөнәсәбәтләренең объектлары һәм субъектлары

**11 статья. Су объекты**

Су объекты яисә аның бер өлеше су мөнәсәбәтләре объекты була.

Җир өсте сулары һәм алар каплап алган, алар янәшәсендәге җирләр (су объектының төбе һәм ярлары) бердәм су объекты буларак карала.

Җир асты сулары һәм алар урнашкан тау токымнары шулай ук бердәм су объекты буларак карала.

**12 статья. Җир өсте су объектлары**

Җир өсте су объектлары җир өсте суларыннан, төпләреннән һәм ярларыннан тора.

Җир өсте су объектлары Татарстан Республикасында җир өсте агым суларына һәм сулыкларына бүленәләр.

**13 статья. Җир асты су объектлары**

Җир асты су объектларына түбәндәгеләр керә:

сулы горизонт - тау токымнары ярыкларында һәм бушлыкларында җыелып торучы һәм гидравлик бәйләнеше булган сулар;

җир асты сулары бассейны - җир астында урнашкан сулы горизонтларның берлеге;

җир асты сулары ятмасы - җир асты суларын чыгару өчен чикләрендә уңай шартлары булган сулы горизонтның бер өлеше;

җир асты суларының табигый чыгуы - коры җирдә яисә су астында җир асты суларының даими чыгып торуы.

**14 статья. Гомуми кулланылыштагы су объектлары**

Гомуми кулланылыштагы су объектлары - бөтен кеше дә килеп йөрерлек һәм файдаланырлык ачык җирдә урнашкан су объектлары.

Гомуми кулланылыштагы су объектларында әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә судан гомуми файдалану гамәлгә ашырыла.

Әгәр су турындагы законнарда турыдан-туры каралган булса, гомуми кулланылыштагы су объектларыннан файдалану чикләнергә дә мөмкин.

Әгәр су саклау турындагы законнарда башкасы каралмаган булса, дәүләт милкендәге су объектлары, шулай ук җирле үзидарә милкендәге аерымланган су объектлары гомуми кулланылыштагы су объектлары булалар.

Физик һәм юридик затлар милкендәге аерымланган су объектлары билгеләнгән тәртиптә милекче ризалыгы белән гомуми кулланылыштагы су объектлары буларак файдаланылырга мөмкин, бу аерымланган су объектына милекчелек хокукын шушылай чикләү бердәм дәүләт реестрында теркәлгән һәм милекчегә тиешле түләүләр бирелгән шартларда гына яисә, милекче үзе хәл итсә генә, түләүсез башкарыла.

Гомуми кулланылыштагы су объектларының яр буйларындагы коры полоса (бечевник) гомуми файдалану өчен билгеләнә. Яр буйларындагы коры полосадан (бечевниктан) һәркем гомуми кулланылыштагы су объекты янында йөрү (транспорттан файдаланмыйча гына) һәм булу өчен, шул исәптән балык тоту һәм суда йөзү чараларын китереп туктату өчен файдалана ала. Яр буйларындагы коры полосаның киңлеге 20 метрдан артмаска тиеш.

**15 статья. Махсус кулланылыштагы су объектлары**

Кешеләрнең чикләнгән даирәсе куллана торган су объектлары махсус кулланылыштагы су объектлары була.

Су объектлары махсус кулланылышка әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә биреләләр.

Су объектларын махсус кулланылышка бирү аларны гомуми кулланылыш су объектлары рәтеннән төшереп калдыруга китерә.

Махсус кулланылыштагы су объектларында яр буйларындагы коры полоса һәм судан гомуми файдалану әлеге Кодексның 14 һәм 38 статьяларында каралган шартларда билгеләнергә мөмкин.

**16 статья. Су объектларының әйләнеше сәләте**

Аерымланган су объектларыннан гайре, дәүләт милкендәге су объектларын дәүләттән аерып алуга китерә торган һәм китерерлек итеп сату, залогка салу һәм алыш-биреш гамәлләре кылу рөхсәт ителми.

Республика милкендәге су объектларыннан файдалану хокуклары бер заттан икенче затка бары тик универсаль хокук дәвамчылыгы тәртибендә генә күчәргә мөмкин.

Аерымланган су объектлары бер заттан икенче затка граждан законнарында һәм җир турындагы законнарда каралган тәртиптә күчәргә мөмкин.

17 статья. **Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсе мөнәсәбәтләренең субъектлары**

Су мөнәсәбәтләрендә катнашучыларга түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы;

районнар, республика буйсынуындагы шәһәрләр, шәһәрләрдәге районнар;

шәһәрләр һәм авыллар, шулай ук җирле үзидарә гамәлгә ашырылучы бүтән территорияләр;

судан файдаланучылар.

Су мөнәсәбәтләрендә, шул исәптән су объектларына милекчелек хокукын гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасы исеменнән әлеге Кодекста билгеләнгән үз компетенциясе чикләрендә дәүләт хакимияте һәм идарәсенең республика органнары катнашалар.

Су мөнәсәбәтләрендә, шул исәптән аерымланган су объектларына милекчелек хокукын гамәлгә ашырганда, районнар, республика буйсынуындагы шәһәрләр, шәһәрләрдәге районнар исеменнән Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары катнашалар.

Шәһәрләр һәм авыллар, шулай ук җирле үзидарә гамәлгә ашырылучы бүтән территорияләр исеменнән су мөнәсәбәтләрендә, шул исәптән су объектларына милекчелек хокукын гамәлгә ашырганда, шушы органнар статусын билгели торган актларда урнаштырылган үз компетенциясе чикләрендә җирле үзидарә органнары катнашалар.

Файдалануларына су объектлары тапшырылган физик һәм юридик затлар судан файдаланучылар булалар.

Судан файдаланучы физик зат су объектларыннан йә үз ихтыяҗлары өчен, йә эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдалана ала. Әгәр әлеге Кодекста башкача каралмаган булса, судан файдаланучы физик зат су объектларыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бары тик судан файдалану лицензиясе алганнан соң һәм тиешле шартнамә төзегәннән соң гына файдаланырга хокуклы.

Әлеге Кодекста башкача билгеләнмәгән булса, судан файдаланучы юридик зат судан файдалану лицензиясе алганнан соң гына су объектларыннан файдаланырга хокуклы.

Су кулланучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен су объектларыннан файдаланучы тиешле эшчәнлекне судан файдалану лицензиясе һәм су объектыннан файдалану шартнамәсе нигезендә генә башкарырга тиеш.

## IV бүлек. Су объектларына милекчелек хокукы

**18 статья. Су объектларына карата милекчелек рәвешләре һәм төрләре**

Татарстан Республикасында су объектлары республика милкендә була.

Коммуналь милек, җирле үзидарә милке һәм хосусый милек аерымланган су объектларына карата гына рөхсәт ителә.

Әлеге Кодекстан башкасы килеп чыкмаса, елганың юлын үзгәртү яисә су объектының урнашкан җирен бүтәнчә үзгәртү су объектына карата милекчелек рәвешен һәм төрен үзгәртүгә китерми.

**19 статья. Су объектларына республика милке хокукы**

Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан су объектлары, су объектларының өлешләре, аларның су ресурслары, шул исәптән коммуналь милектә, җирле үзидарә милкендә һәм хосусый милектә булмаган аерымланган су объектлары республика милкендә булалар. Ресурслары Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе территорияләре чыганаклары исәбеннән формалашкан су объектлары уртак милектә булырга мөмкин. Вәкаләтләрне чикләү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте белән Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасындагы аерым килешүдә билгеләнә.

**20 статья. Аерымланган су объектларына коммуналь милек, җирле үзидарә милке һәм хосусый милек хокукы**

Коммуналь ихтыяҗлар өчен билгеләнгән аерымланган су объектлары коммуналь милектә булырга мөмкин.

Җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен билгеләнгән аерымланган су объектлары җирле үзидарә милкендә булырга мөмкин.

Аерымланган су объектлары физик һәм юридик затлар милкендә булырга мөмкин. Физик һәм юридик затлар милкендә булырга мөмкин булган аерымланган су объектларының иң чик күләмнәре Татарстан Республикасының җир турындагы законнары белән билгеләнә.

Аерымланган су объектлары күчемсез мөлкәткә кертелә һәм җир кишәрлегенең состав өлеше була. Су турындагы законнарның нигезләмәләре әлеге Кодекста каралган очракларда һәм бары тик граждан законнарына, җир турындагы законнарга каршы килмәгән өлешендә генә аерымланган су объектларына карата кулланылалар.

## V бүлек. Су объектларыннан файдалану хокуклары

**21 статья. Су объектлары милекчеләре булмаган затларның су объектларына хокуклары**

Су объектлары милекчеләре булмаган затларның су объектларына хокукларына түбәндәгеләр керә:

озак вакыт файдалану хокукы;

аз вакыт файдалану хокукы;

чикләүле файдалану хокукы (су сервитуты).

Судан файдаланучылар әлеге Кодекста билгеләнгән шартларда һәм чикләрдә су объектларын билиләр һәм алардан файдаланалар.

Хокук мөнәсәбәтләре асылыннан һәм әлеге Кодекстан башкасы килеп чыкмаса, елганың юлын үзгәртү яисә су объектының урнашкан җирен бүтәнчә үзгәртү су объектыннан файдалану хокукын үзгәртүгә яисә туктатып торуга китерми.

**22 статья. Су объектларыннан озак вакыт һәм аз вакыт файдалану хокукы**

Дәүләт милкендәге су объектлары, су объектларыннан файдалану максатларына, объектларының ресурс куәтенә һәм аларның экологик халәтенә карап, физик яисә юридик затларга озак вакыт һәм аз вакыт файдалану өчен биреләләр.

Су объектыннан аз вакыт файдалану хокукы - өч елга кадәр, ә озак вакыт файдалану хокукы өч елдан алып егерме биш елга кадәр билгеләнә.

Су объектыннан файдалану хокукы билгеләнгән тәртиптә судан файдаланучы инициативасы белән озайтылырга да мөмкин.

**23 статья. Су объектыннан чикләүле файдалану хокукы (су сервитуты)**

Су объектыннан чикләүле файдалану хокукы гомуми (публичный) һәм хосусый су сервитуты рәвешләрендә була.

Законнарда башкасы каралмаган булса, гомуми кулланылыштагы су объектларыннан һәм бүтән су объектларыннан һәркем файдаланырга мөмкин (гомуми су сервитуты).

Су объектлары озак вакыт яисә аз вакыт файдалануга бирелгән затларның хокуклары бүтән кызыксынучы затлар файдасына чикләнергә дә мөмкин (хосусый су сервитуты). Хосусый су сервитутлары яклар килешүе буенча йә суд карары нигезендә билгеләнергә мөмкин.

Граждан законнарында каралган сервитутлар турындагы гомуми нигезләмәләр су сервитутларына карата әлеге Кодекс таләпләренә каршы килми торган дәрәҗәдә генә кулланылалар.

**24 статья. Су сервитутларының төрләре**

Гомуми һәм хосусый су сервитутлары түбәндәге максатларда билгеләнергә мөмкин:

корылмаларсыз, техник чараларсыз һәм җайланмаларсыз гына су алу;

терлек-туарга су эчерү һәм куу;

паромнар, көймәләр һәм башка аз сыйдырышлы йөзү чаралары өчен су юллары сыйфатында су объектларын куллану.

Әлеге статьяда каралган су сервитутларына өстәмә буларак су турындагы законнар белән башка су сервитутлары да билгеләнергә мөмкин.

Су сервитутларын гамәлгә ашыру өчен судан файдалану лицензиясен алу таләп ителә.

**25 статья. Җир өсте су объектлары тирәсендәге җир кишәрлекләре милекчеләренең, биләүчеләренең һәм файдаланучыларының хокуклары үзенчәлекләре**

Җир өсте су объектлары тирәсендәге җир кишәрлекләренең милекчеләре, биләүчеләре һәм файдаланучылары үз ихтыяҗлары өчен су объектларыннан бары тик башка затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозмаган килеш кенә файдалана алалар.

Җир өсте су объектлары тирәсендәге җир кишәрлекләренең милекчеләре, биләүчеләре һәм файдаланучылары суднолар йөзүне оештыру өчен һәм, законнарда каралган очраклардан гайре, башка ихтыяҗлар өчен су объектларыннан һәм аларның ярларыннан файдалануга каршы килмәскә тиешләр.

## VI бүлек. Су объектларыннан файдалану хокукларын алу һәм аларны туктату

**26 статья. Су объектларыннан файдалану хокукының барлыкка килү нигезләре һәм су объектларын файдалануга тапшыру тәртибе**

Әгәр әлеге Кодекста башкасы каралмаган булса, җир өсте су объектларыннан файдалану хокукы судан файдалану лицензиясе һәм аның буенча төзелгән су объектыннан файдалану турындагы шартнамә нигезендә алына.

Махсус файдалану режимы билгеләнгәндә, җир өсте су объектларыннан файдалану хокукы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары, судан файдалану лицензиясе һәм лицензия буенча төзелгән су объектларыннан файдалану турындагы шартнамә нигезендә алына.

Судан файдаланучыны - юридик затны үзгәртеп корган очракта җир өсте су объектларыннан файдалану буенча аңа бирелгән хокуклар хокук дәвамчылыгы тәртибендә күчәләр.

Су сервитуты су турындагы законнар яисә шартнамә белән билгеләнә.

Аерымланган су объектларына хокуклар граждан законнарында һәм су турындагы законнарда, шулай ук әлеге Кодекста каралган

тәртиптә алына.

Гомуми су сервитутларыннан гайре, җир өсте су объектларыннан файдалану хокукы су объектыннан файдалану шартнамәсе үз көченә кергән мизгелдән барлыкка килә.

Җир асты су объектларын файдалануга тапшыру, шулай ук җир асты су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге эшчәнлекне лицензияләү, су турындагы законнарның су объектларын файдалануга һәм саклауга куелучы таләпләрен үтәгән килеш, җир асты байлыклары турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә башкарыла.

Су объектлары файдалануга акватория кишәрлекләрен, су алу һәм су агызу урыннарын бүлеп бирү юлы белән, шулай ук законнарда билгеләнгән башка ысуллар белән тапшырылалар.

27 статья. **Су объектларыннан файдалану лицензиясе**

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә лицензияләүне гамәлгә ашырганда су ресурсларының булу-булмавы, аларга карата су кулланучыларның ихтыяҗлары һәм конкрет су объектларының торышы исәпкә алынырга тиеш.

Су объектларыннан файдалану лицензиясе су объектларын берьюлы берничә максатларда файдалану өчен бирелергә мөмкин. Бер үк су объектыннан файдалану өчен судан файдаланучыларның чикләнмәгән даирәсенә лицензияләр бирү рөхсәт ителә, әмма бу шушы су объектына, әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китермәскә һәм гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозмаска тиеш.

Су объектларыннан файдалану хокукы лицензиясендә, су объектыннан файдалану максатларына һәм алымнарына карап, түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

су объекты турында;

судан файдаланучы турында;

су кулланучылар турында;

су объектыннан файдалану максатлары һәм ысуллары турында;

файдалануга бирелүче су объектының яисә аның бер өлешенең җир өстендәге чикләре (координаталары) турында, кирәк чакта су алу (агызу) урыннары турында;

судан файдалану лимитлары турында;

кулланучыларга карата судан файдаланучының йөкләмәләре турында;

лицензиянең гамәлдә булу вакыты турында;

су объектыннан нәтиҗәле файдалану һәм аны саклау буенча таләпләр турында;

лицензияне юкка чыгару шартлары турында.

Судан файдалану лицензияләрен бирү, яңадан рәсмиләштерү, туктатып тору һәм юкка чыгару тәртибе, шулай ук судан файдалану

лицензиясе шартларын дәүләт идарәсенең кызыксынучы органнары белән килештерү тәртибе әлеге Кодекс һәм җир өсте су объектларыннан файдалануга һәм аларны саклауга бәйле эшчәнлекне лицензияләү турында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланучы нигезләмә белән билгеләнә.

28 статья. **Судан файдалану лицензиясен яңадан рәсмиләштерү**

Судан файдалану лицензиясен яңадан рәсмиләштерү судан файдалану шартлары һәм җир өсте су объектының торышы үзгәргән очракта, шулай ук судан файдаланучыны - юридик затны үзгәртеп корган очракларда һәм законда каралган башка очракларда судан файдаланучы инициативасы белән су объектыннан файдалану һәм аны саклау өлкәсендә дәүләт идарәсенең махсус вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла.

Судан файдалану лицензиясен яңадан рәсмиләштерү су объектыннан файдалану шартнамәсенә тиешле үзгәрешләр кертү өчен нигез була.

29 статья. **Судан файдалану лицензиясен юкка чыгару һәм гамәлдә булуын туктатып тору**

Судан файдалану лицензиясе су объектыннан файдалану хокукын туктатуның әлеге Кодексга каралган нигезләрендә су объектыннан файдалану һәм аны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарәсе органы карары буенча аның гамәлдә булу вакыты узганчы ук юкка чыгарылырга мөмкин.

Судан файдалану лицензиясен юкка чыгару шуның нигезендә төзелгән су объектыннан файдалану шартнамәсен өзү өчен нигез була.

Судан файдалану лицензиясенең гамәлдә булуы су объектыннан файдалануны әлеге Кодексга каралган нигезләрдә чикләү яисә туктатып тору очракларында су объектыннан файдалану һәм аны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарәсе органы карары буенча туктатып торылырга мөмкин.

30 статья. **Су объектыннан файдалану шартнамәсе**

Су объектыннан яисә аның бер өлешеннән файдалану һәм аны саклау турында судан файдаланучы белән Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты яисә дәүләт идарәсенең ул вәкаләт тапшырган республика органы тарафыннан төзелгән килешү су объектыннан файдалану шартнамәсе дип таныла.

Судан файдалану лицензиясе бирелгән судан файдаланучы белән су объектыннан файдалану шартнамәсен төзү мәҗбүри була.

Әлеге Кодексга башкасы билгеләнмәгән булса, су объектларыннан файдалану шартнамәләренә карата граждан законнарының нигезләмәләре кулланыла.

Су объектыннан файдалану шартнамәсенең шартлары су объектыннан файдалану һәм аны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы һәм дәүләт идарәсенең башка кызыксынучы органнары белән килештерелергә тиеш. Су объектыннан файдалану шартнамәсен килештерү тәртибе һәм су объектыннан файдалану шартнамәсенең шартларын килештерүче дәүләт идарәсе органнары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Су объектыннан файдалану шартнамәсе судан файдалану лицензиясе нигезендә төзелергә тиеш. Су объектыннан файдалану шартнамәсе судан файдалану лицензиясе шартларына каршы килгән очракта, шулай ук шартнамә нигезләмәләре су турындагы законнар таләпләренә каршы килгән очракта әлеге шартнамә гамәлгә яраксыз дип таныла.

Су объектыннан файдалану шартнамәсе Татарстан Республикасында су объектларыннан файдалану шартнамәләренең дәүләт реестрында теркәлергә тиеш, аны алып бару законнарда билгеләнгән тәртиптә су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

31 статья. **Су объектларыннан файдалану шартнамәләренең төрләре**

Су объектыннан файдалану шартнамәсе түбәндәге төрләрдә төзелергә мөмкин:

су объектыннан озак вакыт файдалану шартнамәсе;

су объектыннан аз вакыт файдалану шартнамәсе;

хосусый су сервитутын билгеләү шартнамәсе.

Су объектыннан озак вакыт файдалану шартнамәсе яисә су объектыннан аз вакыт файдалану шартнамәсе судан файдалану лицензиясе нигезендә төзелә.

Хосусый су сервитутын билгеләүче шартнамә, су объектыннан файдалану хокукы кем файдасына чикләнсә, шул зат белән төзелә.

32 статья. **Су объектыннан файдалану шартнамәсенең мәҗбүри (асылына кагылышлы) шартлары**

Су объектыннан файдалану шартнамәсендә түбәндәгеләр катгый рәвештә күрсәтелергә тиеш:

судан файдалану лицензиясендә каралган шартлар;

су объектыннан файдалану хокукын озайту йә вакытыннан алда туктату тәртибе;

су объектыннан файдалануга бәйле түләүләрнең күләме һәм түләү тәртибе;

төзелгән шартнамә шартларын үтәмәгән өчен якларның җаваплылыгы.

**33 статья. Су объектларыннан файдалану хокукын туктату**

Су объектларыннан файдалану хокукы түбәндәге очракларда туктатыла:

судан файдаланучы су объектларыннан файдаланудан баш тартса;

су объектлары файдалануга тапшырылган вакыт узса;

су объектыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланган физик зат вафат булса;

судан файдаланучы юридик зат бетерелсә;

су объектларыннан махсус файдалану туктатылса;

су объектлары табигый яисә ясалма рәвештә юкка чыкса;

су объектларыннан файдалану хокуклары әлеге Кодекста каралган тәртиптә башка затларга күчсә.

Су объектларыннан файдалану хокукларын мәҗбүриләп туктату бары тик түбәндәге очракларда гына рөхсәт ителә:

су объектлары өч ел буена кулланылмаса;

су ресурслары чикле булганда, су белән тәэмин итү өчен билгеләнгән су объектлары бер ел буена кулланылмаса;

су объектларыннан максатчыл рәвештә файдаланылмаса;

су объектлары дәүләт ихтыяҗлары һәм җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен тартып алынса;

судан файдаланучы судан файдалану лицензиясендә һәм су объектыннан файдалану шартнамәсендә билгеләнгән шартларны һәм таләпләрне үтәмәсә;

су объектларыннан файдалану тыелса.

**34 статья. Су объектларыннан файдалану хокукын туктату тәртибе**

Су объектларыннан файдалану хокуклары судан файдалану лицензиясен юкка чыгару юлы белән су объектыннан файдалану һәм аны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан туктатыла.

Су объектларыннан файдалану хокуклары мәҗбүриләп туктатылган очракта, судан файдаланучыны су турындагы законнарны бозуы һәм аларны билгеләнгән вакытка бетермәве турында кисәткәннән соң судан файдалану лицензиясе юкка чыгарыла.

Судан файдалану лицензиясен юкка чыгару су объектыннан файдалану шартнамәсен өзү өчен нигез була. Шартнамәне төзегән якларга судан файдалану лицензиясен юкка чыгару турында хәбәр иткәннән соң шартнамә төзелгән дип санала.

Су объектларыннан файдалану хокукларын туктату су объектыннан файдалану шартнамәсен граждан законнары нигезендә өзү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Су объектыннан файдалану шартнамәсен өзү судан файдалану лицензиясен юкка чыгару турындагы мәсьәләне карау өчен нигез була.

Махсус кулланылышка бирелгән су объектларыннан файдалану хокукларын туктату Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының судан файдалану лицензиясен юкка чыгару һәм су объектыннан файдалану шартнамәсен өзү өчен нигез була торган су объектларыннан махсус куллануны туктату турындагы карары нигезендә башкарыла.

35 статья. **Су объектларыннан файдалану хокукларын чикләү**

Су объектларыннан файдалану хокуклары дәүләтнең конституциячел корылышын яклау, аның иминлеген тәэмин итү, халыкның сәламәтлеген, әйләнә-тирә табигать мохитен, тарихи-мәдәни мирасны саклау, башка затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау өчен кирәкле дәрәҗәдә әлеге Кодекста һәм башка законнарда каралган очракларда һәм тәртиптә чикләнергә мөмкин.

## VII бүлек. Су объектларыннан файдалану

36 статья. **Судан гомуми һәм махсус файдалану**

Физик һәм юридик затларның корылмалар, техник чаралар һәм җайланмалар кулланмыйча су объектларыннан файдалануы (судан гомуми файдалану) судан файдалану лицензиясе алмыйча гына гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Физик һәм юридик затларның корылмалар, техник чаралар һәм җайланмалар кулланып су объектларыннан файдалануы (судан махсус файдалану) судан файдалану лицензиясе булганда гына гамәлгә ашырыла, моңа аз сыйдырышлы йөзү чараларында йөзү өчен һәм һава судноларын бер мәртәбә төшереп утырту (очырып җибәрү) өчен су объектларыннан файдалану очраклары керми.

Судан махсус файдалану төрләре су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы раслый торган исемлектә билгеләнә.

37 статья. **Су объектларыннан махсус файдалану**

Дәүләт ихтыяҗларын һәм җирле үзидарә ихтыяҗларын тәэмин итү өчен республика милкендәге су объектлары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары буенча махсус файдалануга тапшырылырга мөмкин.

Су объектларын махсус файдалануга тапшыру турындагы карарда су объектларыннан файдалануның максаты һәм төп шартлары күрсәтеләләр.

Су объектларын махсус файдалануга тапшыру тәртибе

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

### 38 статья. Судан гомуми файдалануны гамәлгә ашыру тәртибе

Судан гомуми файдалану су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләре нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнгән шартлар нигезендә, законнарга таянып гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарәнең тиешле органнары белән килештереп, эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү өчен су алу, су коену, аз сыйдырышлы йөзү чараларында йөзү, терлек-туарны эчерү тыелган урыннарны билгелиләр, шулай ук тиешле территорияләрдә урнашкан су объектларында судан гомуми файдалануның бүтән шартларын да урнаштыралар.

Йөзүне тыю һәм судан гомуми файдалануның башка шундый шартларын тыю турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша, махсус мәгълүмати тамгалар яисә бүтән алымнар белән халыкка җиткерелә.

Махсус файдалануга тапшырылган су объектларында судан гомуми файдалану, су объектларыннан файдадану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы белән килештереп, судан файдаланучы билгеләгән шартларда рөхсәт ителә, кирәк чакта, судан файдаланучы моны тыярга да мөмкин. Судан файдаланучы судан гомуми файдалану шартлары турында яисә үзенә махсус файдалануга тапшырылган су объектында аны тыю турында игълан итәргә тиеш. Коммуналь милектәге, җирле үзидарә милкендәге һәм хосусый милектәге аерымланган су объектларында судан гомуми файдалану, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы белән килештереп, милекче билгеләгән шартларда законнар нигезендә рөхсәт ителә. Аерымланган су объекты милекчесе судан гомуми файдалану шартлары яисә аны тыю турында игълан итәргә тиеш.

Әгәр судан гомуми файдалану шартлары яисә аны тыю турында игълан ителмәгән булса, судан гомуми файдалану су турындагы законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Судан гомуми файдалану шартларын һәм аны тыюны игълан итү тәртибе су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

### 39 статья. Судан файдалану (су куллану һәм су бүлү) лимитлары

Судан файдалану (су куллану һәм су бүлү) лимитлары су

объектлары буенча экологик чикләүләр системасы була һәм су ресурсларын тартып алуның яисә җыелма суларны һәм дренаж суларын агызуның, һәм алардагы пычраткыч матдәләр микъдарының иң чик мөмкин күләмнәреннән гыйбарәт була, алар судан файдаланучыга билгеле бер чорга билгеләнәләр.

Судан файдалану (су куллану һәм су бүлү) лимитлары су хуҗалыгы нисбәтләре һәм судан файдаланучыларның су ресурсларына булган ихтыяҗларын игълан итүләре нигезендә билгеләнәләр һәм алар судан файдалану лицензияләрендә күрсәтеләләр.

Судан файдалану (су куллану һәм бүлү) лимитлары су объектларының торышы үзгәрүгә бәйле рәвештә яңадан каралырга мөмкин. Лимитларны үзгәртү судан файдалану лицензиясен билгеләнгән тәртиптә яңадан рәсмиләштерүне таләп итә. Судан файдалану лимитларын яңадан карау тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

### 40 статья. **Судан файдалану өлкәсендә гайре монополия таләпләре**

Судан файдаланучыларның, монополияләштерүгә һәм намуссыз конкуренциягә юнәлтелгән һәм нәтиҗәдә судан башка файдаланучыларның, шулай ук бүтән физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кыса торган яисә кысарга мөмкин булган гамәлләре тыела.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының кабул итә торган карарлары һәм (яисә) кыла торган гамәлләренең нәтиҗәләре судан файдалануны монополияләштерүгә һәм билгеле бер судан файдаланучыларның эшчәнлеге өчен генә дискриминацияле яисә уңай шартлар тудыруга юнәлтерлек яисә судан башка файдаланучыларның, су кулланучыларның, шулай ук бүтән физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозарлык булса, аларга андый карарлар кабул итү һәм (яисә) гамәлләр кылу тыела.

Әгәр судан файдалану лицензияләре, су объектыннан файдалану шартнамәсе судан файдалануны монополияләштерүгә китерә торган, судан башка файдаланучыларның, су кулланучыларның, шулай ук бүтән физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сизелерлек итеп бозуга китерә торган булса, алар билгеләнгән тәртиптә юкка чыгарыла һәм гамәлгә яраксыз дип таныла.

### 41 статья. **Су объектларыннан файдалануны чикләү, туктатып тору яисә тыю**

Гаять аз сулылык очракларында, су объектында һәлакәтле вәзгыятьләрдә, ул билгеләнгән нормадан саекканда, эпидемияләр һәм эпизоотияләр килеп чыгу янаганда, су объектына зарарлы йогынтыларның мөмкин булган иң чик нормативлары артып киткәндә,

шулай ук законнарда каралган башка очракларда кайбер су объектларыннан яисә аларның өлешләреннән файдалану чикләнергә, туктатып торылырга яисә тыелырга мөмкин. Су объектларын куллануны чикләү, туктатып тору яисә тыю турындагы карар су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан кабул ителә.

42 статья. **Су объектларыннан файдаланганда судан файдаланучыларның хокуклары һәм вазыйфалары**

Судан файдаланучылар су объектларыннан файдаланганда түбәндәге хокукларга ия булалар:

үзләренә тапшырылган максатларда су объектларыннан файдалануны гамәлгә ашыру;

су объектыннан файдалануга бәйле хуҗалык эшчәнлеген мөстәкыйль гамәлгә ашыру;

су объектларының торышы турында үзләренең эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә алу;

су турындагы законнарда каралган башка хокукларны гамәлгә ашыру.

Судан файдаланучылар су объектларыннан файдаланганда түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

су объектларыннан нәтиҗәле файдаланырга, судан файдалану лицензиясендә һәм су объектыннан файдалану шартнамәсендә билгеләнгән шартларны һәм таләпләрне үтәргә;

суларның сыйфатын, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларының яшәү мохитен начарайтуга, судан башка файдаланучыларның хокукларын бозуга, шулай ук кешеләр сәламәтлегенә, әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерүгә, хуҗалык объектларына һәм башка объектларга зарар китерүгә юл куймаска;

чистарткыч, гидротехник һәм башка су хуҗалыгы, су саклау корылмаларын һәм техник җайланмаларны төзек хәлдә тотарга, агып төшүче суларны һәм дренаж суларын су объектларына билгеләнгән лимитлардан күбрәк агызып чыгармаска һәм (яисә) зарарлы матдәләре билгеләнгән нормативлардан артыграк булган агып төшүче суларны һәм дренаж суларын агызып чыгармаска;

су объектларының торышына йогынты ясаучы һәлакәтләр һәм башка гадәттән тыш хәлләр турында дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле органнарына билгеләнгән тәртиптә хәбәр итәргә;

су объектлары торышына йогынты ясаучы һәлакәтләрнең һәм башка гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен кисәтү һәм бетерү гамәлләрен вакытында башкарырга;

суда кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен үтәргә;

алынучы, кулланылучы һәм агызып чыгарылучы суларның, алардагы пычраткыч матдәләр микъдарының исәбен билгеләнгән тәртиптә алып барырга, шулай ук су объектларын һәм аларның су саклау зоналарын даими рәвештә күзәтеп торырга һәм бу хактагы мәгълүматны билгеләнгән вакытларда су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органына түләүсез тапшырырга, ә җир асты су объектлары буенча - шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт идарә органына да;

су объектыннан файдалануга бәйле түләүләрне вакытында түләргә;

махсус сакланылучы су объектлары территорияләрендә, су саклау зоналарында, яр буе полосаларында, эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары буларак файдаланылучы, шулай ук табигый дәвалау ресурслары булган су объектларының санитар саклау зоналарында һәм округларында хуҗалык эшчәнлегенең билгеләнгән режимын үтәргә;

су объектларын саклау буенча бүтән гамәлләрне башкарырга.

43 статья. **Судан файдаланучылар хокукларын яклау һәм гарантияләү**

Су объектларыннан файдалануга бәйле хуҗалык эшчәнлегенә һәм судан файдаланучыларның башка төрле эшчәнлегенә дәүләт органнарының тыкшынуы, әлеге Кодекста һәм бүтән законнарда каралган очраклардан гайре, тыела.

Судан файдаланучыларның бозылган хокуклары торгызылырга йә законнарда каралган бүтән тәртиптә якланырга тиеш.

Судан файдаланучыларның хокукларын бозу аркасында китерелгән зыян, алынмый калган табышны да кертеп, тулысынча кире кайтарылырга тиеш.

Республика милкендәге һәм физик һәм юридик затларга файдалануга тапшырылган су объектларын яисә аларның өлешләрен дәүләт ихтыяҗлары өчен яисә җирле үзидарә ихтыяҗлары өчен тартып алу су объектын яисә аның бер өлешен тартып алу аркасында судан файдаланучыга китерелгән зыяннар кире кайтарылганнан соң гына рөхсәт ителә.

## VIII бүлек. Су объектларыннан максатчыл файдалану

44 статья. **Су объектларыннан файдалану максатлары һәм алымнары**

Су объектларыннан түбәндәге максатларда файдаланырга мөмкин:

эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү;

дәвалау, курорт һәм сәламәтләндерү;

сәнәгать һәм энергетика;
авыл һәм урман хуҗалыгы;
гидроэнергетика;
рекреация (ял итү, туризм, һәвәскәр һәм спорт балыкчылыгы, спорт аучылыгы);
су һәм һава юлы транспорты;
төзелеш;
янгын куркынычсызлыгы;
балык хуҗалыгы һәм биоресурсларны чыгару;
аучылык хуҗалыгы;
сал агызу;
файдалы казылмаларны чыгару;
су объектларын һәм аларның биоресурсларын өйрәнү;
җыелма суларны (сәнәгать, авыл хуҗалыгы, коммуналь-көнкүреш, яңгыр сулары һәм башкалар) һәм дренаж суларын агызып чыгару.

Су объектлары файдалану һәм башка максатлар өчен су турындагы законнар нигезендә бирелергә мөмкин.

Су объектлары яисә аларның өлешләре бер үк вакытта бер яисә берничә максат өчен бер яисә берничә файдаланучыга тапшырылырга мөмкин.

Су объектларыннан файдалану су ресурсларын аерып алып та (су алу) йә аларны алмыйча да (су агызып чыгару, су юллары сыйфатында куллану һәм башкалар) гамәлгә ашырылырга мөмкин. Су объектларыннан максатларына һәм алымнарына карап файдалану тәртибе, шартлары һәм үзенчәлекләре әлеге Кодекс һәм бүтән норматив-хокукый актлар белән билгеләнә.

45 статья. **Эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү өчен су объектларыннан файдалану**

Су объектларыннан хуҗалык сулары һәм эчәр сулар белән тәэмин итү өчен файдалану өстенлекле була.

Эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү өчен пычранудан һәм чүпләнүдән сакланылган җир өсте һәм җир асты сулары объектлары файдаланылырга тиеш, аларның сыйфаты билгеләнгән санитария-гигиена таләпләренә туры килергә тиеш. Су объектларының эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү өчен яраклылыгы санитария-эпидемиология күзәтүенең дәүләт органы тарафыннан билгеләнә.

Су объектын эчәр сулар белән тәэмин итү чыганакларына кертү аның ышанычлылыгы һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә санитар саклау зоналарын һәм округларын оештыру мөмкинлеге исәпкә алынып башкарылырга тиеш.

Әлеге статьяның **5** өлешендә каралган очраклардан гайре, эчәр сулар белән тәэмин итү өчен яраклы җир асты су объектларыннан башка максатларда файдалану рөхсәт ителми.

Хуҗалык һәм башка максатлар өчен куллану өчен җир өсте су объектлары булмаган, әмма җир астында эчәр сулар белән тәэмин итү өчен яраклы суларның җитәрлек запаслары булган территориядә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органының җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт идарә органы белән килештерелгән тәкъдиме нигезендә аерым очракларда гына шушы суларны эчәр сулар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган максатларда кулланырга рөхсәт итәргә мөмкин.

Үзәкләштерелгән челтәрләрдән эчәр сулар белән тәэмин итүнең сыйфатын дәүләт тарафыннан тикшереп торуны санитария-эпидемиология күзәтүенең дәүләт органы гамәлгә ашыра.

### 46 статья. Эчәр сулар белән тәэмин итүнең резерв чыганаклары

Гадәттән тыш экологик яисә башка төр экстремаль хәлләр барлыкка килгәндә, халыкны эчәр сулар белән тәэмин итү өчен пычранулардан сакланылган җир өсте һәм җир асты сулары базасында су белән тәэмин итүнең резерв чыганаклары булдырыла. Бу чыганаклар өчен аларны саклау һәм аларның торышын тикшереп тору өчен су турындагы һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә махсус режим урнаштырыла.

### 47 статья. Халыкны үзәкләштерелгән һәм үзәкләштерелмәгән рәвештә эчәр сулар белән һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү

Халыкны үзәкләштерелгән рәвештә эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин иткәндә су объектларыннан су алуны эшчәнлекләре эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү предметы һәм максаты булган һәм судан файдалану лицензиясе булган оешмалар гамәлгә ашыралар.

Эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән халыкны үзәкләштерелмәгән рәвештә тәэмин иткәндә физик һәм юридик затлар су алуны турыдан-туры җир өсте һәм җир асты су объектларыннан су турындагы законнар һәм җир асты байлыклары турындагы законнар нигезендә гамәлгә ашырырга хокуклы.

### 48 статья. Су объектларыннан дәвалау, курорт һәм сәламәтләндерү өчен файдалану

Табигый дәвалау ресурслары булган су объектлары беренче чиратта авыруларны дәвалауга һәм профилактикалауга бәйле һәм

халыкның ялына бәйле максатлар өчен законнар нигезендә файдаланылалар.

Аерым очракларда Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, дәүләт экология һәм санитария-эпидемиология экспертизасының уңай бәяләмәсе булганда һәм бу тиешле территориянең курорт-рекреация потенциалына зыян китермәсә генә, табигый дәвалау ресурслары булган су объектларыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә башка максатлар өчен дә файдалануны рөхсәт итәргә мөмкин.

**49 статья. Су объектларыннан сәнәгать һәм энергетика өчен файдалану**

Су объектларыннан сәнәгать һәм энергетика өчен файдаланучылар су алуны һәм югалтуны кимәтү, су объектларының пычрануын, чүпләнүен һәм бетәшүен булдырмау чараларын күрергә, шулай ук су объектларының температура режимын саклауны тәэмин итәргә тиеш.

Табигый бәла-казалар, һәлакәтләр һәм башка гадәттән тыш хәлләр очрагында, шулай ук су объектларыннан сәнәгать һәм энергетика өчен файдаланучылар су куллануның судан файдалану лицензиясендә билгеләнгән лимитын арттырып җибәргән очракта, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тәкъдиме буенча су турындагы законнардагы таләпләр нигезендә сәнәгать һәм энергетика өчен су объектларыннан файдалануны чикләргә, туктатып торырга яисә тыярга мөмкин.

**50 статья. Су объектларыннан авыл һәм урман хуҗалыгы өчен файдалану**

Су объектларыннан авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы өчен файдаланучы физик һәм юридик затлар мелиоратив (сугару) челтәрендәге суларның юкка сарыф ителүен һәм агып чыгуын кимәтә торган, сугару челтәренә балыклар эләгүен булдырмый торган чаралар күрергә һәм кирәк очракларда грунт суларының пычрануын һәм өскә күтәрелүен кисәтә торган гамәлләр башкарырга тиеш.

Киптерү, сугару, шул исәптән норматив сыйфатка ия булган җыелма сулар белән сугару, киптерү һәм су объектларыннан файдалануга бәйле башка мелиоратив эшләр су объектларын һәм су җыю мәйданнарын дренаж суларыннан һәм агып төшүче сулардан саклауны тәэмин итә торган табигатьне саклау гамәлләре комплексында башкарылырга тиеш.

Терлек фермалары, комплекслары, агросәнәгать предприятиеләре, ягулык-майлау материалларының, минераль ашламаларның һәм агулы химикатларның складларының үзләре биләгән территорияләре киртәләнгән булырга, су объектларын,

аларның су җыю мәйданнарын пычранудан саклый торган чистарткыч корылмалары һәм санитар-яклау зоналары булырга тиеш.

**51 статья. Су объектларыннан гидроэнергетика өчен файдалану**

Гидроэнергетика өчен су объектларыннан файдалану судан бүтән файдаланучыларның мәнфәгатьләрен исәпкә алып һәм су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау таләпләрен үтәгән килеш гамәлгә ашырыла.

Сусаклагычларда һәм табигый сулыкларда гидротехник корылмаларны эксплуатацияләүче оешмалар, эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итүнең өстенлеген, шулай ук, балыкларның аеруча кыйммәтле төрләрен үрчетү өчен махсус әһәмияткә ия елга участокларында балык хуҗалыгы ихтыяҗларын исәпкә алып, сусаклагычларны су белән тутыру һәм эшләтү режимын тәэмин итәргә тиешләр.

Сусаклагычларны эксплуатацияләү, алардан файдалану һәм аларны саклау тәртибе, шулай ук сусаклагычларны эксплуатацияләү кагыйдәләренең үтәлешен тикшереп тору тәртибе законнар белән билгеләнә.

**52 статья. Су объектларыннан су, һава транспорты һәм сал агызу өчен файдалану**

Җир өстендәге су объектлары гомуми кулланылыштагы су юллары булалар, моңа бу максатлар өчен файдалану тулысынча яисә өлешчә тыелган йә аерым файдалануга бирелгән су объектлары керми.

Суднолар йөртү, сал агызу, һава суднолары очып китү (очып төшү) өчен файдалануга яраклы категориясенә кертелгән су объектлары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Суднолар йөртү өчен файдаланылучы су объектларында судноларга такмыйча сал агызу тыела. Су объектларында берәмләп сал агызу тыела.

Аз сыешлы йөзү судноларында йөзү, шулай ук һава судноларын очып китү (очып төшү) өчен су объектларыннан файдалану Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

**53 статья. Су объектларыннан балык хуҗалыгы һәм биоресурслар чыгару өчен файдалану**

Балыкларны һәм башка биоресурсларны саклап калу, торгызу һәм чыгару өчен аеруча әһәмиятле су объектлары яисә аларның участоклары гадәттә балык хуҗалыгын алып бару һәм биоресурслар чыгару өчен бирелә. Бу очракларда, эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш

сулары өчен су белән тәэмин итүдән гайре, су объектларыннан һәм аларның участокларыннан башка максатлар өчен файдалану су турындагы законнар нигезендә чикләнергә мөмкин.

Балыкларны һәм башка биоресурсларны саклау, торгызу яисә чыгару өчен билгеләнгән су объектларының яисә аларның участокларының исемлеге табигый байлыклардан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Су объектларыннан балык хуҗалыгы өчен һәм биоресурслар чыгару өчен файдаланучы юридик һәм физик затлар файдалана торган урыннардагы яр буйларын законнарда билгеләнгән таләпләргә туры китереп тотарга тиешләр.

Балык хуҗалыгы һәм биоресурслар чыгару өчен файдаланылучы су объектларында гидротехник һәм башка корылмаларны урнаштырганда, проектлаштырганда, төзегәндә, реконструкцияләгәндә һәм эксплуатацияләгәндә су объектларын, балыкларны һәм башка биоресурсларны, су тирәлегендәге хайваннарны һәм үсемлекләрне саклауны тәэмин итә торган гамәлләр, шулай ук аларны торгызу шартлары күздә тотылырга һәм вакытында башкарылырга тиеш.

Балык хуҗалыгы өчен һәм биоресурслар чыгару өчен су объектларыннан файдалану үзенчәлекләре законнар белән билгеләнә.

54 статья. **Су объектларыннан аучылык хуҗалыгы өчен файдалану**

Аучылык объектларына кертелгән кыргый су кошларының һәм су тирәлегендәге кошларның, кыйммәтле мехлы җәнлекләрнең яшәү тирәлеге урыннары булган су объектлары хайваннар дөньясыннан файдалану лицензиясе булган физик һәм юридик затларга су турындагы законнар һәм хайваннар дөньясын саклау, аннан нәтиҗәле файдалану турындагы законнар нигезендә файдалануга тапшырыла.

55 статья. **Су объектларыннан рекреация (ял итү, туризм, спорт, һәвәскәр һәм спорт балыкчылыгы) максатларында файдалану**

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы һәм санитария-эпидемиология күзәтүенең дәүләт органы белән килештереп, дәүләт идарәсенең җирле органнары яисә җирле үзидарә органнары билгеләгән урыннарда, суда кешеләр гомерен саклау буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләрне үтәгән килеш, су объектлары рекреация (ял итү, туризм һәм спорт) максатларында файдаланыла.

Һәвәскәр һәм спорт балыкчылыгы өчен су объектларыннан файдалану (моңа су турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә балык тоту тыелган башка урыннар керми) балыкчылык кагыйдәләрен үтәгән килеш рөхсәт ителә.

56 статья. **Су объектларыннан янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен файдалану**

Теләсә кайсы су объектыннан, шул исәптән аерымланган су объектларыннан, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен су алу рөхсәт ителә, бу исә янгынны сүндерү өчен кирәкле микъдарда түләүсез һәм бернинди махсус рөхсәтсез башкарыла.

Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен махсус билгеләнгән су объектларыннан бүтән максатларда су алу тыела.

57 статья. **Су объектларыннан файдалы казылмалар чыгару, төзелеш ихтыяҗлары һәм бүтән эшләр башкару өчен файдалану**

Су объектларыннан файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмалары төзү һәм эксплуатацияләү, бораулау эшләре башкару өчен файдалану җир асты байлыклары турындагы Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Кодекс нигезендә гамәлгә ашырыла.

Торф һәм сапропель, ком һәм гравий чыгару, баткан агачларны өскә чыгару, кабель һәм торбаүткәргечләр сузу, су төбен тирәнәйтү, шартлату эшләре һәм су объектлары төбеннән файдалануга, су асты һәм су өсте корылмаларын төзүгә һәм эксплуатацияләүгә бәйле бүтән эшләр башкару өчен судан файдалануга билгеләнгән тәртиптә бирелә торган лицензия нигезендә гамәлгә ашырыла.

58 статья. **Җыелма суларны һәм дренаж суларын агызып чыгару өчен су объектларыннан файдалану**

Җыелма суларны һәм дренаж суларын агызу өчен су объектларыннан файдалану су объектларына чыгарылучы агып төшүче суларны һәм дренаж суларын чистарткач һәм зарарсызландыргач кына һәм билгеләнгән нормативлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Су объектларына агызылучы җыелма суларга катнаштыру өчен чиста су куллану, җыелма суларны яңгыр сулары агып төшә торган канализация юлларына агызу, шулай ук җирлек рельефына агызып чыгару тыела.

Составы һәм җирле шартлары исәпкә алынып, экологик, агротехник, санитария һәм ветеринария нормалары үтәлгән килеш, әйләнештәге су белән тәэмин итү системаларына җибәрергә мөмкин булган җыелма суларны су объектларына агызып чыгару рөхсәт ителми.

Җыелма суларны һәм дренаж суларын табигый дәвалау ресурслары булган һәм махсус сакланылучыларга кертелгән түбәндәге су объектларына агызу тыела:

эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү өчен файдаланылучы яисә файдаланырлык җир өсте су объектларына;

су җыйгычларның санитар саклау зоналарына һәм округларына;

курортларның беренче һәм икенче санитар (тау-санитар) саклау зоналарына;

туризм, спорт һәм халыкның күпләп ял итү урыннарына;

кыйммәтле һәм махсус сакланылучы балыкларның уылдык чәчү, һәм кышлау чокырларына;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән кыйммәтле хайваннарның һәм үсемлекләрнең тереклек итү урыннарына. Җыелма суларны һәм дренаж суларын агызу өчен су объектларыннан файдалану әлеге Кодекснын 41 статьясы нигезендә чикләнергә, туктатып торылырга яисә тыелырга мөмкин.

Халыкның сәламәтлегенә яисә су һәм су тирәлеге хайваннарының һәм үсемлекләренең яшәешенә куркыныч яный башласа, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнары, санитария-эпидемиология күзәтүенең дәүләт органы, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы җыелма суларны һәм дренаж суларын законнарда билгеләнгән тәртиптә туктатып торырга тиешләр, хәтта хуҗалык объектлары һәм башка объектлар да эксплуатацияләнүдән туктатылырга мөмкин.

## IX бүлек. Су объектларын саклау

### 59 статья. Су объектларын саклауга куелучы гомуми таләпләр

Су объектлары пычранудан, диффуз (җир өсте һәм һава аша пычрану) пычрануны да кертеп, чүпләнүдән һәм бетәшүдән сакланырга тиеш. Су объектларының су җыю мәйданнары да законнарда билгеләнгән тәртиптә пычранудан һәм чүпләнүдән сакланырга тиеш.

Су объектларыннан файдаланганда физик һәм юридик затлар су объектларын саклауны тәэмин итүче җитештерү-технологик, мелиорация, агротехника, гидротехника, санитария гамәлләрен һәм башка гамәлләрне үтәргә тиеш.

Эшчәнлекләре су объектлары торышына йогынты ясаучы судан файдаланучылар, башка физик һәм юридик затлар су объектларына зарарлы йогынтының билгеләнгән иң чик мөмкин нормативларыннан тыш су объектларын пычратмаска һәм чүпләмәскә, шулай ук су

объектларының бетәшүенә китерә торган итеп су ресурсларын аерып алмаска тиешләр.

Су объектларының пычрануын кисәтү һәм бетерү максатларында пычрату чыганаклары билгеләнә, җир өсте һәм җир асты суларының сыйфатын начарайта, аларны куллануны чикли, шулай ук су объектлары төбенә һәм ярларына тискәре тәэсир итә торган зарарлы матдәләрне су объектларына агызучы яисә аны башкача кертүче объектлар шундый чыганаклар булып танылалар.

Су объектларын пычранудан саклау стационар пычрату чыганаклары һәм пычратуның башка чыганаклары эшчәнлеген җайга салу аша гамәлгә ашырыла.

Җитештерү һәм куллану калдыкларын су объектларына агызып чыгару һәм күмү тыела.

Су объектларын саклауга таләпләр су турындагы законнар, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендәге законнар, санитария законнары һәм башка законнар белән билгеләнә.

**60 статья. Су объектлары төбендәге эшчәнлек белән су объектларын пычратудан һәм чүпләүдән саклау**

Су объектлары төбеннән файдалы казылмалар чыгару яисә су объекты төбенә утыртып корылмалар төзү җир өсте суларына, су объектлары төбенә, ярларына һәм су биоресурсларына зарарлы йогынты ясамый торган ысуллар белән башкарылырга тиеш.

Су объектлары төбендә җир асты байлыкларыннан файдалануга юнәлдерелгән, әмма файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган эшләр башкарганда, җир асты байлыкларыннан файдаланучылар су объектларын пычратмаска, чүпләндермәскә һәм саегайтмаска тиешләр.

**61 статья. Су объектлары өстендә файдаланылучы суднолар һәм башка чаралар, корылмалар белән су объектларын пычратудан һәм чүпләүдән саклау**

Су объектлары өстендәге үзйөрешле судноларны, шулай ук башка объектларны шушы судноларда һәм объектларда барлыкка килүче җыелма суларны, калдыкларны һәм ташландыкларны җыю җайланмалары булмаган килеш эксплуатацияләү рөхсәт ителми.

**62 статья. Су объектларын радиоактив һәм агулы матдәләр (материаллар) белән пычратудан саклау**

Су объектларында радиоактив һәм агулы матдәләр (материаллар) халыкның сәламәтлегенә, шулай ук әйләнә-тирә табигать мохитенә зарар китерми торган дәрәҗәдә булырга тиеш.

Су объектларына радиоактив һәм агулы матдәләр (материаллар) күмү һәм агызу тыела.

Су объектларының радиоактив һәм агулы матдәләр (материаллар) белән пычрану дәрәҗәсен дәүләт тарафыннан тикшереп торуны шуңа махсус вәкаләтле дәүләт органнары, шулай ук әйләнә -тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы гамәлгә ашыра.

63 статья. **Су объектларын агулы химикатлар һәм башка химик чаралар белән пычратудан саклау**

Авыл хуҗалыгында һәм бүтән хуҗалык эшчәнлегендә агулы химикатлар һәм башка химик чаралар куллану, әгәр бу су объектлары һәм су биоресурслары торышына тәэсир итмәсә генә, рөхсәт ителә.

64 статья. **Су объектлары торышына йогынты ясаучы хуҗалык объектларын һәм башка объектларны проектлаштырганда, урнаштырганда, төзегәндә, үзгәртеп корганда һәм эксплуатацияләүгә тапшырганда куелучы экологик таләпләр**

Хуҗалык объектларын һәм башка объектларны проектлаштырганда, урнаштырганда, төзегәндә, үзгәртеп корганда һәм эксплуатацияләүгә тапшырганда, шулай ук яңа технологик процессларны гамәлгә ашырганда, аларның су объектлары торышына һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә йогынтысы исәпкә алынырга тиеш.

Су объектлары торышына йогынты ясаучы хуҗалык объектларын һәм башка объектларны төзү өчен урыннар билгеләү, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнары, санитария-эпидемиология күзәтүенең дәүләт органы, дәүләт идарәсенең бүтән кызыксынучы органнары белән килештереп, законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Яңа төзелүче һәм үзгәртеп корылучы гамәлдәге хуҗалык объектларын һәм башка объектларны проектлаштырганда һәм төзегәндә, шулай ук су объектлары торышына йогынты ясаучы яңа технологик процессларны гамәлгә керткәндә техник су белән тәэмин итүнең ябык системасын төзүне күздә тотарга кирәк.

Техник су белән тәэмин итүнең турыдан-туры агызу системаларын проектлаштыру һәм төзү аерым очракларда гына һәм бары тик проект алды һәм проект документларына дәүләт экспертизасының һәм дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе булганда гына әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан рөхсәт ителә.

Җир асты суларында су җыю һәм дренаж корылмаларын проектлаштырганда, урнаштырганда һәм эксплуатацияләгәндә җир

өсте су объектларына, туфрак, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы торышына йогынтының иң чик мөмкин нормалары үтәлергә тиеш.

Түбәндәгеләрне эксплуатацияләүгә тапшыру тыела: су объектларын пычранудан, чүпләнүдән, бетәшүдән һәм су

ларның зарарлы йогынтысыннан саклаучы җайланмалар һәм чистарту корылмалары белән җиһазландырылмаган һәм су объектлары торышына йогынты ясаучы хуҗалык объектларын, башка объектларны, шул исәптән фильтр тупланмаларын, сәнәгать һәм көнкүреш калдыкларын күмү урыннарын, шәһәр чүпләрен һәм башка чүп-чар җыю урыннарын;

балыкларны саклау җайланмалары булмаган һәм җыелып агызыла торган суларны исәпкә алуны тәэмин итүче җайланмалары булмаган корылмаларны;

чистарту корылмалары һәм санитар саклау зоналары булмаган терлекчелек фермаларын һәм башка җитештерү комплексларын;

суларның зарарлы йогынтысын булдырмау гамәлләрен уздырганга кадәр сугару, суландыру һәм киптерү системаларын, сусаклагычларны, плотиналарны, каналларны һәм башка гидротехник корылмаларны һәм ясалма су объектларын, шул исәптән аерымланган су объектларын;

балыкларны саклау җайланмалары, ташу суларын һәм балыкларны тотып кала торган җайланмалары булмаган гидротехник корылмаларны;

суны көйләү җайланмалары белән һәм суны исәпкә алу приборлары белән җиһазландырмаган җир асты суларын җыюга бәйле корылмаларны;

санитар саклау зоналары билгеләнмәгән һәм су объектлары торышы күрсәткечләрен күзәтү пунктлары булдырылмаган килеш су җыю корылмаларын һәм башка гидротехник корылмаларны;

су объектларының пычрануын булдырмый кала торган чаралар һәм нефть продуктлары, химик һәм башка продуктлар агып чыгуны билгеләү өчен тикшерү-үлчәү аппаратурасы белән җиһазландырылмаган нефть продуктлары, химик һәм башка продуктлар ташу һәм саклау корылмаларын, җайланмаларын;

су объектлары торышының күрсәткечләрен күзәтү пунктлары булдырылмаган килеш җыелма сулар белән сугару объектларын. Су басуга әзерлек буенча проектларда каралган гамәлләр башкарылганчы сусаклагычларны су белән тутыру тыела.

Су объектларына йогынты ясаучы хуҗалык объектларын һәм башка объектларны эксплуатацияләүгә тапшыру турындагы карарны Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, дәүләт идарәсенең җирле органнары законнарда билгеләнгән тәртиптә кабул итәләр.

**65 статья. Су объектлары торышына йогынты ясаучы хуҗалык объектларын һәм башка объектларны эксплуатацияләү**

Су объектлары торышына йогынты ясаучы хуҗалык объектларын һәм башка объектларны эксплуатацияләгәндә физик һәм юридик затлар су объектларының пычрануын, чүпләнүен һәм бетәшүен һәм суларның зарарлы йогынтысын булдырмый торган чаралар күрергә тиеш.

Хуҗалык объектларын һәм башка объектларны эксплуатацияләгәндә түбәндәгеләр тыела: җыелма суларны һәм дренаж суларын билгеләнгән нормативлар нигезендә чистартмаган һәм зарарсызландырмаган килеш су объектларына агызу;

су объектларының торышына шактый йогынты ясарлык итеп алардан су алу;

иң чик мөмкин концентрацияләре билгеләнмәгән яисә йогышлы авырулар таратучы матдәләр булган җыелма суларны һәм дренаж суларын агызу.

Су объектларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану таләпләрен бозган өчен су объектлары торышына йогынты ясаучы хуҗалык объектларын һәм башка объектларны эксплуатацияләү законнарда билгеләнгән тәртиптә чикләнә, туктатып торыла яисә бөтенләй туктатыла.

**66 статья. Җир асты су объектларын саклау таләпләре**

Эшчәнлекләре җир асты сулары торышына зарарлы йогынты ясый торган яисә ясарга мөмкин булган юридик һәм физик затлар җир асты су объектларының пычрануын, чүпләнүен һәм бетәшүен һәм суларның зарарлы йогынтысын булдырмау чараларын күрергә тиешләр.

Эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү өчен кулланыла торган яисә кулланылырга мөмкин булган һәм табигый дәвалау ресурсларыннан торган җир асты су объектларының су җыю мәйданнарында калдыклар күмү, чүплекләр, зиратлар, терлек күмү урыннары һәм җир асты сулары торышына йогынты ясаучы башка объектлар урнаштыру рөхсәт ителми.

Әгәр җир асты су объектларына йогынты ясый торган булса яисә ясарга мөмкин булса, җирләрне җыелма сулар белән сугару тыела.

Җыелма суларны һәм дренаж суларын җыю өчен скважиналар урнаштыру һәм аларны эксплуатацияләү, шулай ук файдалы казылмаларның эшкәртелгән ятмаларыннан файдалану су турындагы законнарда һәм җир асты байлыклары турындагы законнарда каралган таләпләрне үтәгән килеш кенә рөхсәт ителә.

Бораулау скважиналары, шул исәптән үзлегеннән агып чыгучы һәм разведкалау скважиналары, шулай ук эксплуатацияләүгә яраксыз

яисә кулланылуы туктатылган скважиналар билгеләнгән тәртиптә көйләү җайланмалары белән җиһазландырылырга, консервацияләнергә яисә ябылырга тиеш.

Әгәр җир асты байлыкларыннан файдаланганда җир астында сулы горизонтлар ачылса, җир асты байлыкларыннан файдаланучы билгеләнгән тәртиптә җир асты су объектларын саклау чараларын күрергә һәм бу хакта дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарына, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнарына, җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау идарәсенең дәүләт органына, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органына хәбәр итәргә тиешләр.

Файдалы казылмалар чыгарганда, суны киметү эшләрен башкарганда, корылмалар төзегәндә яисә суларның зарарлы йогынтысыннан саклаганда, шулай ук сугарылган җирләрдә дренаж системаларын төзегәндә һәм аларны эксплуатацияләгәндә җир асты суларын аерып алу җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясе булганда гына рөхсәт ителә, анда су турындагы законнар таләпләре нигезендә җир асты су объектларын куллануга бәйле аерым шартлар билгеләнә. Җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясендә җир асты су объектларын куллануга кагылышлы шартлар су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә килештерелергә тиеш.

Җир асты су объектларын куллануга бәйле су җыю корылмаларын урнаштырганда, проектлаштырганда, төзегәндә, аларны эксплуатацияләүгә тапшырганда һәм эксплуатацияләгәндә җир өсте су объектларына һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә зарарлы йогынтыны булдырмау чаралары күздә тотылырга тиеш.

### 67 статья. Җир асты су ятмалары мәйданнарын төзү шартлары

Торак пунктлары, сәнәгать комплекслары һәм башка хуҗалык объектлары проектлаштыру һәм төзү шушы төзелеш башкарылачак кишәрлекләрдәге җир куенында җир асты суларының булмавын җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт идарә органы раслаганнан соң гына җир асты байлыклары турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә рөхсәт ителә.

Эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү өчен яраклы һәм табигый дәвалау ресурслары булган җир асты сулары ятмалары мәйданнарын төзү җир асты суларын аерып алу мөмкинлеге тәэмин ителгәндә генә, шулай ук җир асты су объектларын пычранудан, чүпләнүдән һәм бетәшүдән саклауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашырганда гына рөхсәт ителә.

**68 статья. Су объектларында һәм аларның су саклау зоналарында эшләр башкару тәртибе**

Су объектларында яисә аларның су саклау зоналарында төзелеш эшләре, тирәнәйтү һәм шартлату эшләре һәм башка эшләр су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы белән килештереп алып барыла.

Су объектларында эшләр башкарганда килеп чыгучы файдалы казылмалардан һәм башка ресурслардан файдалану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

**69 статья. Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә нормалаштыру**

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә нормалаштыруга түбәндәгеләр керә:

судан файдалануга (су куллануга һәм су бүлеп бирүгә) лимитлар билгеләү;

су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә стандартлар, нормативлар һәм кагыйдәләр әзерләү һәм аларны кабул итү.

Җир өсте һәм җир асты суларын экологик таләпләргә туры килерлек халәттә тоту су объектларына иң чик мөмкин зарарлы йогынтыларның нормативларын билгеләп һәм үтәп тәэмин ителә.

Су объектларына зарарлы йогынтыларның иң чик мөмкин нормативлары түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

дәвамлы йогынтысы су объектының экосистемасын үзгәртүгә китерми торган антропоген йөкләнешнең иң чик мөмкин күләменнән;

су объектына һәм аның су җыю мәйданына үтеп керерлек зарарлы матдәләрнең иң чик мөмкин массасыннан, бу чакта су объектларындагы зарарлы матдәләрнең иң чик мөмкин концентрацияләрен арттыру рөхсәт ителми.

Су объектларындагы, җыелма сулардагы һәм дренаж суларындагы зарарлы матдәләрнең иң чик мөмкин концентрацияләренең нормативлары су объектыннан максатчыл файдалану шартларыннан чыгып билгеләнә.

Су объектларына зарарлы йогынтыларның иң чик мөмкин нормативларын эшләү һәм раслау тәртибе законнар нигезендә билгеләнә.

**70 статья. Җир өсте суларын агызуның һәм аларны бөтенләй юк итүнең иң чик нормаларына экологик таләпләр**

Су объектлары торышын экологик таләпләргә туры китереп саклау, су объектларының үз-үзләрен торгызу сәләтен саклау максатларында сулар агызып чыгарыла һәм җир өсте суларын бөтенләй юк итүнең иң чик мөмкин күләме билгеләнә.

Җир өсте суларын агызуның һәм аларны бөтенләй юк итүнең иң чик мөмкин күләмнәре су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан законнарда билгеләнә торган тәртиптә һәр су объекты өчен аерым-аерым билгеләнә.

Судан файдаланучыларның су ресурсларына булган ихтыяҗларын су агызу исәбенә канәгатьләндерү рөхсәт ителми.

71 статья. **Су саклау зоналары**

Су саклау зоналары җир өсте су объектларын экологик таләпләргә туры килерлек халәттә тоту, аларның пычрануын, чүпләнүен һәм бетәшүен булдырмау, шулай ук үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеген саклау өчен билгеләнәләр.

Су объекты акваториясе белән янәшә территория су саклау зонасы була, анда табигать ресурсларыннан файдалануның һәм аларны саклауның һәм башка хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның махсус режимы билгеләнә.

Су саклау зоналары чикләрендә яр буе саклау полосалары билгеләнә, аларда җирләрне сөрү, печән чабу, урман кисү һәм төпләү, терлек көтүләре йөртү һәм терлекләр өчен җәйләүләр оештыру һәм, әлеге Кодексга каралган очраклардан гайре, башка эшчәнлек тыела.

Су саклау зоналарының яр буе саклау полосаларында, судан файдалану лицензиясе булганда, су белән тәэмин итү объектлары, рекреация объектлары, балыкчылык һәм аучылык хуҗалыклары объектлары, шулай ук су җыю һәм порт корылмалары, гидротехник корылмалар урнаштыру рөхсәт ителә.

Су саклау зоналарының, яр буе саклау полосаларының күләмнәрен һәм чикләрен билгеләү тәртибе, алардан файдалану режимы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Су объектларының хуҗалык сулары һәм эчәр сулар белән тәэмин итү чыганаклары булган һәм аеруча кыйммәтле балык төрләре өчен уылдык чәчү урыннары булган су саклау зоналары билгеләнгән тәртиптә махсус сакланылучы табигать территорияләре категориясенә кертелә.

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы су саклау зоналарының, яр буе саклау полосаларының күләмнәрен һәм чикләрен, алардан файдалану режимын билгеләү буенча карарлар кабул итү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша, махсус мәгълүмат тамгалары ярдәмендә һәм башка ысуллар белән барлык кызыксынучы гражданнарга һәм юридик затларга җиткерергә тиеш.

**72 статья. Су саклау зоналарындагы җир кишәрлекләрен кулланга тапшыру үзенчәлекләре һәм алардан файдалануны тикшереп тору**

Су саклау зоналарындагы, шул исәптән утраулардагы җир кишәрлекләре, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы белән килештереп, Татарстан Республикасының җир турындагы законнарында билгеләнгән тәртиптә, бары тик су белән тәэмин итү, рекреация, балыкчылык хуҗалыгы объектлары, су җыю һәм порт корылмалары, гидротехник корылмалар урнаштыру өчен генә бирелә.

**73 статья Су саклау зоналарындагы урманнардан файдалануга һәм аларны саклауга таләпләр**

Су объектларының су саклау зоналарындагы урманнардан файдалану һәм аларны саклау су объектларының пычрануын, чүпләнүен һәм бетәшүен булдырмауга юнәлтелгән.

Су саклау зоналарындагы һәм яр буе саклау полосаларындагы урманнарда тоташтан урман кисү тыела. Урманны аралаштырып кисү һәм су объектларын саклауны тәэмин итә торган башка урман хуҗалыгы гамәлләре рөхсәт ителә.

Су саклау зоналарындагы урманнарны файдалануга тапшыру, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы белән килештереп, урман һәм су турындагы законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы су саклау зоналарындагы урманнардан файдалануны тикшереп тора һәм ул су объектлары торышына зарарлы йогынты ясаучы эшләрне законнарда билгеләнгән тәртиптә туктатып торырга йә тыярга хокуклы.

**74 статья. Җир асты байлыкларыннан файдаланганда су объектларын саклауга куелучы таләпләр**

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнгәндә, файдалы казылмалар чыгарганда, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмалары төзегәндә һәм аларны эксплуатацияләгәндә, җир асты байлыкларыннан файдаланучылар су объектларының сакланышын тәэмин итәргә, хуҗалык эшчәнлеген һәм башка эшчәнлекне су объектларының пычрануын, чүпләнүен һәм бетәшүен булдырмый торган ысуллар белән алып барырга тиешләр.

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы су объектлары акваториясе һәм бассейны чикләрендәге, аларның су саклау зоналары территорияләрендәге җир асты байлыкларыннан файдалануны тикшереп тора һәм ул су объектларының торышына зарарлы йогынты

ясый торган җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне туктатып торырга йә бөтенләй туктырга хокуклы.

75 статья. **Санитар саклау зоналары һәм округлары**

Эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү өчен файдаланылучы һәм табигый дәвалау ресурслары булган су объектларын саклау максатларында санитар саклау зоналары һәм округлары билгеләнә.

76 статья. **Су объектларында гадәттән тыш экологик хәлләр һәм экологик бәла-казалар зоналары**

Хуҗалык эшчәнлеге яисә кешенең бүтән төр эшчәнлеге йә табигый процесслар нәтиҗәсендә кешеләр сәламәтлегенә, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына, әйләнә-тирә табигать мохите торышына куркыныч тудыручы су объектлары, аларның өлешләре һәм су җыю мәйданнары экологик хәлләр һәм экологик бәла-казалар зоналары итеп игълан ителәләр.

Гадәттән тыш экологик хәлләр яисә бәла-казалар зоналарының хокукый режимы законнар белән билгеләнә.

77 статья. **Суларның зарарлы йогынтысының нәтиҗәләрен кисәтү һәм бетерү**

Дәүләт идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары һәм судан файдаланучылар суларның зарарлы йогынтысының нәтиҗәләрен кисәтү һәм бетерү өчен чаралар күрергә тиешләр.

Суларның зарарлы йогынтысы нәтиҗәләрен кисәтү һәм бетерү буенча кичектергесез чаралар күрүне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан төзелә торган ташуга каршы комиссияләр һәм башка комиссияләр оештырылырга мөмкин. Бу комиссияләрнең үз вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән карарларын дәүләт идарәсенең барлык органнары, җирле үзидарә органнарының, барлык физик һәм юридик затларның үтәүләре мәҗбүри.

Су объектларындагы табигый бәла-казалар, һәлакәтләр булганда судан файдаланучылар, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы, дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары белән килешеп, суларның тискәре нәтиҗәләрен кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр уздыруда катнашырга тиеш.

78 статья. **Махсус сакланылучы су объектлары**

Махсус сакланылучы су объектлары - табигатьне саклау, ресурсларны сак тоту, фәнни, мәдәни, эстетик, рекреация һәм савыктыру ягыннан аеруча әһәмияткә ия табигый су экосистемасы ул.

Махсус сакланылучы су объектлары законнар нигезендә даими яисә вакытлыча хуҗалык эшчәнлегеннән тулысынча яки өлешчә аерып алыналар.

Махсус сакланылучы су объекты махсус сакланылучы аерым табигать территориясе йә махсус сакланылучы аерым табигать территориясенең бер өлеше булырга мөмкин.

Махсус сакланылучы су объектларының категорияләре, шулай ук махсус сакланылучы су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау тәртибе махсус сакланылучы табигать территорияләре һәм су турындагы законнар белән билгеләнә.

## X БҮЛЕК. СУ ОБЪЕКТЛАРЫННАН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ АЛАРНЫ САКЛАУ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕ ҺӘМ ТИКШЕРЕП ТОРУЫ

### 79 статья. Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт идарәсе принциплары

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт идарәсе түбәндәге принципларга нигезләнә:

су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт идарәсе вазыйфаларын һәм аларны хуҗалыкта куллану вазыйфаларын чикләү;

су объектларыннан нәтиҗәле файдалануның һәм аларны саклауның бассейн һәм административ-территория принципларын бергә алып бару;

су объектларыннан файдалануга физик һәм юридик затларның тигез хокуклылыгын һәм суларның сыйфатын экологик һәм санитар таләпләргә туры килерлек халәттә саклаган хәлдә судан файдалануның оптималь шартларын тәэмин итү.

### 80 статья. Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт идарәсен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы гамәлгә ашыралар.

### 81 статья. Су хуҗалыгы балансдары

Су хуҗалыгы балансдары аерым бер территориядә суга булган ихтыяҗ белән су ресурсларын чагыштыручы исәпләү материалларыннан гыйбарәт.

Су хуҗалыгы балансдары түбәндәгеләр өчен билгеләнә: су объектлары бассейннары, административ-территория берәмлекләре һәм аларның аерым участоклары буенча су ресурсларының булу-булмавы һәм аларның кулланылыш дәрәҗәсен бәяләү өчен;

су ресурсларына киләчәктәге ихтыяҗларны канәгатьләндерү һәм бердәм дәүләт су фондыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аны

саклауны тәэмин итү буенча су хуҗалыгының төп гамәлләрен планлаштыру өчен.

Су хуҗалыгы балանслары су объектлары бассейннары буенча, административ-территория берәмлекләре буенча су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан төзелә.

82 статья. **Су ресурсларыннан комплекслы файдалану һәм аларны саклау схемалары**

Су ресурсларыннан комплекслы файдалану һәм аларны саклау схемаларына су ресурслары торышы турында һәм су объектларын киләчәктә файдалану һәм саклау турында тикшеренүләр һәм проект эшләнмәләре буенча системалаштырылган материаллар керә.

Су ресурсларыннан комплекслы файдалану һәм аларны саклау схемалары җәмгыятьнең су ресурсларына киләчәктәге ихтыяҗларын канәгатьләндерү, су объектларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны тәэмин итү, шулай ук суларның тискәре йогынтысын булдырмый калу һәм бетерү өчен су хуҗалыгы гамәлләрен һәм башка гамәлләрне билгеләү максатларында эшләнә.

Су ресурсларыннан комплекслы файдалану һәм аларны саклау схемалары су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан эшләнә.

Су ресурсларыннан комплекслы файдалану һәм аларны саклау схемаларын эшләү, килештерү, аларга дәүләт экспертизасы ясау, аларны раслау һәм гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

83 статья. **Су объектларын нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт программалары**

Су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә гамәлләрне планлаштыру су хуҗалыгы баланслары, су ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау схемалары, Татарстан Республикасының дәүләт су кадастры белешмәләре нигезендә башкарыла һәм су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт программалары кысаларында гамәлгә ашырыла.

Су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт программаларын эшләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

84 статья. **Су объектларының дәүләт мониторингы**

Су объектларының дәүләт мониторингы табигый һәм техноген факторлар йогынтысы нәтиҗәсендә су объектларының торышын һәм аның үзгәрүен даими күзәтеп тору системасыннан гыйбарәт, ул

алынган әлеге мәгълүматны тискәре процессларны үз вакытында ачыклау, аларның үсешен фаразлау, зарарлы нәтиҗәләрне булдырмый калу һәм гамәлгә ашырылучы су саклау гамәлләренең нәтиҗәлелеген бәяләү максатларында, шулай ук кызыксынучы затларны һәм халыкны су объектларының пычрану дәрәҗәсе турында агымдагы һәм ашыгыч мәгълүмат белән, су объектларының торышы турында кисәтүләр һәм фаразлаулар белән тәэмин итү максатларында, җыюны, тапшыруны һәм эшкәртүне тәэмин итә.

Су объектларының дәүләт мониторингы Татарстан Республикасының әйләнә-тирә табигать мохите мониторингы бердәм системасының төп өлешен тәшкил итә һәм Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең вәкаләтле органнары тарафыннан уздырыла. Су объектларының дәүләт мониторингы өлкәсендәге эшләрне җайга салу әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Су объектларының дәүләт мониторингын гамәлгә ашыру тәртибе законнар белән билгеләнә.

85 с т а т ь я . **Суларны дәүләт исәбенә алу**

Суларны дәүләт исәбенә алу территорияләр буенча су ресурсларының исәбен һәм сыйфатын билгеләнгән тәртиптә системалы ачыклаудан һәм фиксацияләүдән гыйбарәт.

Суларны дәүләт исәбенә алу агымда һәм киләчәктә су объектларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны планлаштыруны тәэмин итү максатларында башкарыла.

Суларны дәүләт исәбенә алу белешмәләре җир өсте һәм җир асты су объектларының сыйфат һәм сан күрсәткечләре буенча торышын, аларның өйрәнелү һәм кулланылу дәрәҗәсе буенча торышын билгели.

Суларны дәүләт исәбенә алу, гидрометеорология һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау мониторингы өлкәсендә дәүләт идарәсе органы (җир өсте су объектлары буенча) һәм җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт идарәсе органы (җир асты су объектлары буенча) катнашында, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан Россия Федерациясендәге бердәм система буенча гамәлгә ашырыла, ул җир өсте һәм җир асты суларыннан файдалануны исәпкә алу турында судан файдаланучылар бирә торган белешмәләргә һәм су объектларының дәүләт мониторингы белешмәләренә нигезләнә.

86 с т а т ь я . **Татарстан Республикасының дәүләт су кадастры**

Дәүләт су кадастры Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан су объектлары һәм аларның ресурслары турында системалаштырылган белешмәләр җыелмасыннан гыйбарәт, аларның

саны-сыйфаты, географик тасвирламасы, классификациясе, өйрәнелү дәрәҗәсе күрсәтелә, шулай ук судан файдаланучылар һәм су ресурсларыннан файдалану турында белешмәләр бирелә.

Татарстан Республикасының дәүләт су кадастры өч бүлектән тора:

- җир өсте сулары;
- җир асты сулары;
- су ресурсларыннан файдалану.

Татарстан Республикасының Дәүләт су кадастрын алып бару гидрометеорология һәм әйләнә-тирә табигать мохите мониторингы өлкәсендә дәүләт идарә органы (җир өсте су объектлары буенча) һәм җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә дәүләт идарә органы (җир асты су объектлары буенча) катнашында, су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан Россия Федерациясенең бердәм системасы буенча гамәлгә ашырыла һәм суларны дәүләт исәбенә алу белешмәләренә нигезләнә.

87 статья. **Су объектлары торышына йогынты ясаучы хуҗалык объектларын һәм башка объектларны төзүнең һәм үзгәртеп коруның проект алды һәм проект документларына дәүләт экспертизасы. Дәүләт экология экспертизасы**

Су объектлары торышына йогынты ясаучы хуҗалык объектларын һәм башка объектларны төзүнең һәм үзгәртеп коруның проект алды һәм проект документларына дәүләт экспертизасы шул документларның проектлаштыру һәм төзү буенча норматив документлардагы башлангыч мәгълүматларга, техник шартларга һәм таләпләргә туры килүен тикшерүдән гыйбарәт.

Су объектлары торышына йогынты ясаучы хуҗалык объектларын һәм башка объектларны төзүнең һәм үзгәртеп коруның проект алды һәм проект документларына дәүләт экспертизасы су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт экспертизасын уздыру тәртибе закон белән җайга салына.

Норматив-хокукый актларның, социаль-икътисадый, фәнни-техник, инвестицион комплекслы һәм максатчыл программаларның һәм башка программаларның проектлары, житештерү көчләрен күчерү һәм оештыру схемалары, табигатьтән файдалану һәм аны саклау схемалары; оешмаларны һәм хуҗалык эшчәнлегенең башка объектларын төзүнең, үзгәртеп коруның, киңәйтүнең, техник җиһазлауның, консервацияләүнең һәм бетерүнең техник-икътисадый нигезләүләре һәм проектлары, файдаланганда су объектлары торышына һәм аларның биоресурсларына турыдан-туры йә читләтеп

йогынты ясарлык хуҗалык эшчәнлеген һәм башка эшчәнлекне нигезләүче бүтән төр документлар су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт экспертизасын узарга тиеш.

Судан файдалануга лицензия бирү бары тик дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе булганда гына рөхсәт ителә.

Дәүләт экология экспертизасы законнар нигезендә уздырыла.

**88 статья. Су объектларыннан файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан тикшереп тору**

Су объектларыннан файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан тикшереп тору бурычлары түбәндәгеләрне үтәүне тәэмин итүдән гыйбарәт:

су объектларыннан файдалануны һәм аларны саклау тәртибен;

судан файдалану (су куллану һәм су бүлү) лимитларын;

су объектларыннан файдалануны һәм аларны саклау өлкәсендәге стандартларны, нормативларны һәм кагыйдәләрне;

эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү чыганаклары буларак кулланылучы, шулай ук табигый дәвалау ресурслары булган махсус сакланылучы су объектлары территорияләрендә, су саклау зоналарында, яр буе полосаларында, су объектларының санитар саклау зоналарында һәм округларында хуҗалык эшчәнлеге режимын;

су турындагы законнарның башка таләпләрен.

Су объектларыннан файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан тикшереп торуны су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең башка органнары үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыралар.

**89 статья. Су объектларыннан файдалануны һәм аларны саклауны җитештерү ягыннан һәм иҗтимагый тикшереп тору**

Су объектларыннан файдалануны һәм аларны саклауны җитештерү ягыннан һәм иҗтимагый тикшереп торуны судан файдаланучылар, бүтән юридик һәм физик затлар, иҗтимагый берләшмәләр законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыралар.

**90 статья. Су хуҗалыгы эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу**

Су хуҗалыгы эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуны су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы гамәлгә ашыра. Су хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашырганда су хуҗалыгы объектларын Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә дәүләт унитар предприятиеләренә хуҗалык итүгә һәм оператив идарәгә

тапшыру рөхсәт ителә.

Күрсәтелгән дәүләт унитар предприятиеләрен төзү, үзгәртеп кору, бетерү граждан законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## XI бүлек. Су объектларыннан файдалануны һәм аларны саклауны икътисадый җайга салу

### 91 статья. Су объектларыннан файдалануны һәм аларны саклауны икътисадый җайга салу

Су объектларыннан файдалануны һәм аларны саклауны икътисадый җайга салуга түбәндәгеләр керә:

су объектларыннан файдалануга бәйле түләүләр системасын билгеләү;

су объектларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны икътисадый кызыксындыру;

су объектларын саклауны финанслау системасын төзү.

### 92 статья. Судан файдалануның түләүле булуы

Су объектларыннан файдалану, әлеге Кодексга каралган очраклардан тыш, түләүле була. Судан файдалануның түләүле булуы су ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм су объектларын саклауны кызыксындыру максатында билгеләнә.

Җир асты су объектларыннан файдаланган өчен түләүләр - җир асты байлыклары турындагы Татарстан Республикасы законнары, ә җыелма суларны һәм дренаж суларын җир асты су объектларына агызып чыгарган өчен түләүләр әлеге Кодекс һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Җир өсте суларын фильтрлы су җыйгычлар (яр буе скважиналары, үзәннәрдәге корылмалар) белән аерып алганда түләүләр җир өсте су объектларыннан файдаланган өчен түләүләр кебек алына. Чишмә суларын җир өсте су җыйгычлары белән аерып алганда түләүләр җир асты су объектларыннан файдаланган өчен түләүләр кебек алына.

Федераль милектәге су объектларыннан файдаланган өчен түләүләр федераль законнар нигезендә билгеләнә һәм алына, шулай ук бюджетлар арасында бүленә.

Аерымланган су объектлары өчен түләү законнарда каралган тәртиптә билгеләнә һәм алына.

### 93 статья. Су объектларыннан файдалануга бәйле түләүләр системасы

Су объектларыннан файдаланган өчен түләүләр системасына түбәндәгеләр керә:

җир өсте су объектларыннан файдаланган өчен түләү (су өчен салым);

су объектларын саклауга юнәлтелгән түләүләр;
судан файдалану лицензияләре биргән өчен җыем.

Җир өсте су объектларыннан файдалануга бәйле түләүләрне шушы эшчәнлекне башкаручы физик һәм юридик затлар башкара, ул эшчәнлекне башкару өчен аларның судан файдалану лицензияләре булырга тиеш.

Җир өсте су объектларыннан файдалануга бәйле түләүләр судан файдалану рөхсәт ителгән чорда бер мәртәбә түләнү торган яисә даими кертемнәр рәвешендә кертеләләр.

Су объектларыннан файдалануга бәйле түләүләрне билгеләү һәм алу тәртибе, шулай ук акчаларны бюджетлар арасында бүлү Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

**94 статья. Җир өсте су объектларыннан файдаланган өчен түләүләр (су өчен салым)**

Су объектларыннан файдаланган өчен түләү (су өчен салым) түбәндәгеләр өчен салына:

су объектыннан билгеләнгән лимит чикләрендә су алган өчен;
су объектыннан лимиттан тыш су алган өчен;
су объектыннан су ресурсларын аерып алмыйча файдаланган өчен.

Суны лимиттан тыш алган өчен арттырылган түләү билгеләнә, ул судан файдаланучы карамагында калучы табыш исәбеннән түләнә.

**95 статья. Су объектларын саклауга юнәлтелгән түләүләр**

Су объектларын саклауга юнәлтелгән түләүләр су объектларын пычраткан өчен түләүдән һәм су ресурсларын торгызган өчен бүленүче суммалардан тора.

Су объектларын пычраткан өчен түләү түбәндәгеләр өчен алына:

җыелма суларны һәм дренаж суларын норматив сыйфатлы су объектына билгеләнгән лимит чикләрендә агызып чыгарган өчен;

зарарлы матдәләре билгеләнгән нормативлардан артып китә торган җыелма суларны һәм дренаж суларын су объектына агызып чыгарган өчен;

җыелма суларны һәм дренаж суларын су объектына билгеләнгән лимиттан тыш агызган өчен;

җыелма суларны һәм дренаж суларын су объектына авария хәлендә агызып чыгарган өчен.

Зарарлы матдәләре иң чик мөмкин концентрациядән өч тапкыр һәм аннан да күбрәк булган җыелма суларны һәм дренаж суларын җир өсте һәм җир асты су объектларына ниятләмәстән берьюлы агызу авария хәлендә агызу дип таныла.

Җыелма суларны һәм дренаж суларын билгеләнгән лимиттан тыш агызып чыгарган яисә нормативка туры килми торган суларны агызган өчен арттырылган түләү билгеләнә, ул судан файдаланучыда

калучы табыш исәбеннән түләнә.

Су ресурсларын торгызган өчен түләү суммаларын җир өсте су объектларыннан суны аерып алучылар түлиләр.

Су объектларын пычраткан өчен һәм су ресурсларын торгызган өчен Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелүче түләүләр Татарстан Республикасының Экологик фондын төзүгә җибәрелә һәм су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыру; су объектларын нәтиҗәле файдалану һәм саклау гамәлләрен финанслау; суларның зарарлы йогынтысыннан саклау; дәүләт мониторингы, суларны исәпкә алу һәм дәүләт су кадастрын алып бару; фәнни-тикшеренү һәм проект эшләре башкару; су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә һәм гадәттән тыш хәлләрдә суларның тискәре йогынтыларын бетерү өлкәсендә экологик тәрбияләү һәм белем бирү, шул исәптән кадрлар әзерләү өчен, шулай ук су объектларыннан нәтиҗәле файдалануга һәм аларны саклауга бәйле башка максатлар өчен кулланыла.

**96 статья. Судан файдалану лицензияләре биргән өчен җыем**

Судан файдалану лицензияләре биргән өчен җыем су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тарафыннан алына.

Судан файдалану лицензияләре биргән өчен җыем күләме су объектларыннан файдалану заявкаларын экспертизалау чыгымнарыннан, лицензия бирүгә бәйле оештыру чыгымнарыннан һәм башка чыгымнардан чыгып билгеләнә һәм су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

**97 статья. Су объектларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны икътисадый кызыксындыру**

Су объектларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны икътисадый кызыксындыруга түбәндәгеләр керә:

су объектларын саклау буенча, суларның зарарлы йогынтысын булдырмый калу һәм бетерү буенча эшләр башкаручы юридик һәм физик затларга; су объектларыннан, аларның биоресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны тәэмин итүче фәнни-техник казанышларга ирешүчеләргә; суны сак тоту җиһазлары һәм тикшерү-үлчәү приборлары, шулай ук су объектларына пычраткыч матдәләр агызуны арттырмыйча экологик чиста продукция җитештерүчеләргә бирелә торган салым ташламаларын һәм башка өстенлекле ташламаларны билгеләү;

су объектларын, аларның биоресурсларын саклау, суларның зарарлы йогынтысын булдырмый калу һәм бетерү буенча эшләрне башкару өчен ташламалы кредитлар бирү;

судан файдаланучыларга бирелгән салым, кредит ташламалары һәм башка өстенлекле ташламалар билгеләү.

Су объектларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өчен салым, кредит ташламалары һәм башка өстенлекле ташламалар бирү тәртибе законнар белән билгеләнә.

**98 статья. Җир өсте су объектларыннан файдалануга бәйле түләүләр буенча ташламалар**

Җир өсте су объектларыннан файдаланган өчен түләүләр су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт идарә органыннан алынмый.

Авыл хуҗалыгы өчен су объектларыннан файдаланучыларга җир өсте су объектларыннан файдалануга бәйле түләүләрнең ташламалы күләмнәре билгеләнә.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән судан файдаланучыларга ташламалар, шулай ук судан файдаланучыларның башка категорияләренә җир өсте су объектларыннан файдалануга бәйле түләүләр буенча ташламалар законнар белән билгеләнә.

## XII бүлек. Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге бәхәсләрне хәл итү

**99 статья. Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге бәхәсләрне хәл итү**

Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендәге бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

## XIII Бүлек. Су турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

**100 статья. Су турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык**

Су турындагы законнарны бозган өчен физик һәм юридик затлар законнар нигезендә җаваплы булалар.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән җаваплылыкка җәлеп итү гаепле затларны бозган хокукларын төзәтүдән һәм китерелгән зыянны түләүдән азат итми.

**101 статья. Су объектларына зыян китергән өчен физик һәм юридик затларның җаваплылыгы**

Су объектларына һәм аларның су саклау зоналарына зыян китергән физик һәм юридик затлар аларны элекке халәтенә кайтарырга,

ә моны эшләү мөмкин булмаганда, китерелгән зыянны тулысынча түләргә тиешләр.

Су турындагы законнарны бозу аркасында су объектларына, аларның биоресурсларына һәм су саклау зоналарына китерелгән зыянны түләү билгеләнгән тәртиптә расланган таксалар һәм зыян күләмен исәпләү ысулиятләре нигезендә, ә алар булмаганда - китерелгән зыянны, шул исәптән алынмый калган табышны да исәпкә алып, су ресурсларының бозылган халәтен торгызу өчен кирәкле фактик чыгымнар буенча ирекле рәвештә башкарыла йә ул суд карары буенча түләттерелә.

Су турындагы законнарны бозу аркасында су объектларына китерелгән зыянны түләтү турындагы дәгъваларны су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы, җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт идарә органы, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органы, санитария-эпидемиология күзәтүенең дәүләт органы белдерергә хокуклы.

Суд карары буенча алынучы зыян түләү суммалары билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм җирле бюджетларына күчерелә, һәм алар су объектларын торгызу өчен тотыла.

Су турындагы законнарны бозу аркасында су объектларына китерелгән зыянны түләү шартлары һәм тәртибе законнар белән җайга салына.

### 102 статья. **Су объектларына зыян китерүне кисәтү**

Әлеге статьяның 101 статьясында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары, дәүләт хакимиятенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик затлар су объектларына зыян китерә торган һәм киләчәктә зыян китерү куркынычын тудыра торган хуҗалык эшчәнлеген һәм башка эшчәнлекне чикләү, туктатып тору яисә туктату турында судка законнарда билгеләнгән нигезләрдә һәм тәртиптә дәгъвалар белдерергә хокуклы.

## XIV БҮЛЕК. СУ ОБЪЕКТЛАРЫННАН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ АЛАРНЫ САКЛАУ ӨЛКӘСЕНДӘ ХАЛЫКАРА ШАРТНАМӘЛӘР

### 103 статья. **Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә халыкара шартнамәләр**

Әгәр су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән халыкара шартнамәдә әлеге Кодекстагыдан бүтәнрәк кагыйдәләр билгеләнгән булса, ул чакта халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

## XV Бүлек. ЙОМГАК НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

**104 статья. Әлеге Кодексны гамәлгә кертү**

Әлеге Кодексны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты үзенең норматив-хокукый актларын әлеге Кодекска яраклаштырырга тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 июне
№ 2221

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 669. Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле рәвештә «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

1 статья. Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү чараларын Татарстан Республикасының республика бюджетын үтәгәндә өстәмә алынган керемнәр исәбеннән финанслау максатларында «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998 ел, №12; 1999 ел, №6) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1999 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын керемнәр буенча 13197103 мең сум күләмендә һәм чыгымнар буенча 13839256 мең сум күләмендә расларга.

1999 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 642153 мең сум күләмендә билгеләргә.».

2. 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасының республика бюджетына агымдагы чыгым-

нарны финанслау өчен ассигнованиеләрнең гомуми күләмен - 8044384 мең сум дип, үсеш бюджетын финанслау өчен, капитал салуларны да кертеп, 5794872 мең сум, дип билгеләргә.».

22 статьяның 1 абзацындагы 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт хакимиятенә һәм идарәсенә, 224583 224583».

4. 25 статьяда:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1999 елга дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны 224583 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең, шул исәптән: | 7566 |
| киткәннәре урынына Татарстан Республикасының яңа халык депутатларын сайлауларны үткәрүгә | 800 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә | 4766 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны әзерләүгә һәм үткәрүгә | 1200». |

5. 43 статьяга түбәндәге сүзләрне өстәргә: «Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү чыгымнары».

2 с т а т ь я . Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көннән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2340

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 670. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясенең көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы егерменче пленар сес-

сиясенең түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны билгеләү турында.

2. Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне финанслау турында.

3. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе составын раслау турында.

4. Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасы депутатларын бер мандатлы сайлау округлары буенча сайлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча округ сайлау комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында.

5. «Дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

6. «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

7. «Гадәттән тыш хәлнең хокукый режимы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

8. «Татарстан Республикасының Законнар җыелмасы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

9. «Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

10. «Татарстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

11. «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны туктатып тору турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

12. «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте вәкиллекле органнары һәм дәүләт идарәсе органнары хезмәткәрләренең хезмәт хаклары күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

13. «Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты - Татарстан Республикасы Хөкүмәте структурасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

14. «Татарстан Республикасының матбугат, телерадиотапшырулар эшләре һәм массакүләм коммуникация чаралары министры урынына З.Р.Вәлиева кандидатурасын килештерү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

15. «З.Р.Вәлиеваның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

16. «Татарстан Республикасы халык депутаты А.Ә.Камаловны Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими нигездә эшләүдән азат итү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2338

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 671. Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны билгеләү турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 68, 89 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны 1999 елның 19 декабрендә якшәмбе көнгә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар көнендә тавыш бирүне 8 сәгатьтән 20 сәгатькә кадәр үткәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2339

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 672. Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе составын раслау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясен түбәндәге составта расларга:

**Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе**

| | |
|---|---|
| Сираев Марат Әшраф улы | Татарстан Республикасының элеккеге составтагы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе |

**Үзәк сайлау комиссиясе әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Водопьянова Татьяна Павловна | «Сәүдә берлеге» сәүдә, җәмәгать туклануы, куллану чылар кооперациясе һәм эшкуарлык хезмәткәрләре һөнәр берлегенең Татарстан республика комитеты рәисе |
| Гусева Любовь Акимовна | Татарстан Республикасының элеккеге составтагы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе урынбасары |
| Каменькова Валентина Николаевна | Татарстан Республикасының элеккеге составтагы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе секретаре |
| Кадыйров Илдар Эдгар улы | «Хөррият» фондының юридик sхезмәте башлыгы |
| Казыйханов Илдар Гәрәйхан улы | «Казан вертолет заводы» АҖ һөнәр берлеге комитеты рәисе |
| Рахманов Илдус Васил улы | Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары |
| Романов Николай Александрович | «Ак Барс» банкының Бөгелмә филиалы директоры |
| Романова Раиса Петровна | Чаллы шәһәре сугыш һәм хезмәт ветераннары пансионаты директоры |
| Салабаев Альберт Михайлович | Татарстан Республикасының юстиция министры |
| Фатыйхов Илсур Мәхмүт улы | вакытлыча эшләми |
| Феоктистов Игорь Геннадьевич | Хәзерге заман гуманитар институтының Казан филиалы студенты |

| | |
|---|---|
| Хәйруллов Дамир Сәйфулла улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты урынбасары |
| Йосыпов Раиф Әюп улы | пенсионер, Чаллы шәһәре |
| Якупов Эдуард Закирҗан улы | Казан дәүләт медицина университетының студентлар һөнәр берлеге комитеты рәисе |

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2341

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 673. Россия Федерациясе Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча округ сайлау комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында

«Россия Федерациясе Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның 20 статьясындагы 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. 22 нче Әлмәт сайлау округының округ сайлау комиссиясе әгъзаларының яртысын түбәндәге составта билгеләргә:

| | |
|---|---|
| Есипов Юрий Александрович | «Татнефть» ААҖ һөнәр берлеге комитеты рәисе урынбасары |
| Зыятдинов Рамил Госман улы | «Сарман» газетасы редакторы |
| Кириллов Николай Александрович | Бөгелмә районының «АЭРЪ» сәнәгать сәүдә-финанс компаниясенең ЧҖҖ генераль директоры ның хокукый мәсьәләләр буенча ярдәмчесе |
| Лизунов Олег Николаевич | «Нурлатнефть» НГЧИ һөнәр берлеге комитеты рәисе |
| Миңневәлиев Рим Назыйф улы | Ютазы юл-ремонтлау төзелеш идарәсе башлыгы |
| Муллагалиев Илдус Рафис улы | Әлмәт шәһәре һәм Әлмәт районы ның салым инспекциясе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Юдина Надежда Валентиновна | Азнакай шәһәренең хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәге директоры |

2. 23 нче Мәскәү сайлау округының округ сайлау комиссиясе әгъзаларының яртысын түбәндәге составта билгеләргә:

| | |
|---|---|
| Дриго Владислав Васильевич | Халык депутатларының Зеленодол берләштерелгән Советы юрисконсульты |
| Ибраһимова Леора Хим кызы | пенсионер, Казан шәһәре |
| Морозова Ольга Николаевна | пенсионер, Казан шәһәре |
| Сәйфуллин Ренад Нигъмәтулла улы | «Казан моторлар төзү житештерү берләшмәсе» АЖнең баш метрологы |
| Батурин Владимир Павлович | Дәүләт Думасы депутаты ярдәмчесе, Казан шәһәре |
| Турулов Валерий Николаевич | «Казан моторлар төзү житештерү берләшмәсе» АЖнең баш юрисконсульты |
| Хәбибуллина Миләүшә Камил кызы | «Сафьян» АЖ һөнәр берлеге комитеты рәисе, Казан шәһәре |

3. 24 нче Чаллы сайлау округының округ сайлау комиссиясе әгъзаларының яртысын түбәндәге составта билгеләргә:

| | |
|---|---|
| Дренясов Вячеслав Семенович | Чаллы шәһәре һәм төбәк буенча Сәүдә-сәнәгать палатасы вице-президенты |
| Исрафилов Ирек Хөснимәрдан улы | Кама политехника институтының гидропневматика һәм җылылык техникасы кафедрасы доценты |
| Коба Любовь Ильинична | Чаллы шәһәренең «Союзпечать» ЧЖЖ директоры |
| Мазунина Роза Ивановна | «Чаллы» кошчылык фабрикасы юрисконсульты |
| Пинчук Людмила Анатольевна | 58 нче «Тополек» мәктәпкәчә балалар учреждениесе тәрбиячесе, Чаллы шәһәре |
| Ряднов Анатолий Дмитриевич | Алабуга шәһәренең сууткәр |

| | |
|---|---|
| | геч-канализация хуҗалыгы җитештерү идарәсе юрисконсульты |
| Хәбиров Равил Зөфәр улы - | Менделеев районының баш архитекторы |

4. 25 нче сайлау округының округ сайлау комиссиясе әгъзаларының яртысын түбәндәге составта билгеләргә:

| | |
|---|---|
| Гарипов Роберт Зарип улы | «Арскнефтепродукт» АҖ генераль директоры |
| Ихсанова Зөлфирә Котдус кызы | «Росгосстрах-Татарстан» ИАҖнең Саба филиалы директоры |
| Насыйбуллин Сәмигулла Шәрифулла улы | «Лесная» ял базасы учреждениесе директоры, Түбән Кама шәһәре |
| Никулин Владимир Викторович | Биек Тау районы почта элемтәсе узелы башлыгы |
| Прокопьева Римма Михайловна | Түбән Кама районы һәм Түбән Кама шәһәре администрациясенең торак мәйданны исәпкә алу һәм бүлү бүлеге мөдире |
| Павлов Николай Александрович | «Нижнекамскнефтехим» АҖ механигы |
| Смирнов Павел Александрович | Мамадыш районы администрациясенең гомуми бүлеге мөдире |

5. 26 нчы Идел буе сайлау округының округ сайлау комиссиясе әгъзаларының яртысын түбәндәге составта билгеләргә:

| | |
|---|---|
| Алиәкбәров Хәсән Хәсән улы | «Таттазселькомплект» ЧҖҖ маркетинг инженеры, Казан шәһәре |
| Васильева Флюра Алексеевна | Вахитов районы администрациясенең әйдәүче белгече |
| Ионова Наталья Николаевна | 25 нче урта мәктәп директоры, Казан шәһәре |
| Кибардин Александр Михайлович | Арбузов исемендәге ОФХИ лабораториясе мөдире, Казан шәһәре |
| Марков Валерий Валентинович | «Искож» Казан заводы» ЯАҖ генераль директоры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Сальников Евгений Николаевич | «Риэлстелт» фирмасы ЧҖШ директоры |
| Телешова Наталья Евгеньевна | Казан «Горэлектротранспорт» ҖБ җыемнар хезмәте кассиры |

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2342

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 674. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны туктатып тору турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Төньяк Кавказда бөтен Россия Федерациясе һәм аның халыклары язмышы өчен үтә куркыныч юнәлештә үсә баручы сәяси хәл белән бәйле рәвештә тирән шөбһә һәм борчылганлыгын белдерә. Чечен конфликтын җайга салуның озакка китүе котылгысыз рәвештә бүген хокукый тәртипсезлек зонасының киңәюенә, халыкара террорлык көчләренең Россия республикаларының эчке эшләренә актив тыкшынырга маташуына китерә.

Хәрби-сәяси каршылык орбитасына инде Дагыстанның байтак өлеше тартып кертелде. Террорлык актлары нәтиҗәсендә йөзләрчә һәм меңнәрчә кешеләр йорт-җирсез калдылар, байтак торак пунктлары җир йөзеннән юк ителде. Сугышчан хәрәкәтләр барышында федераль коралды көчләр җитди югалтуларга дучар ителәләр. Кайтарып алгысыз югалтулар кайгысы күп кенә россиялеләрнең, Татарстан Республикасы гражданнарының йортларына һәм гаиләләренә килеп җитте. Буйнак һәм Мәскәү шәһәрләрендәге террорлык актлары бернинди гаепсез йөзләгән кешеләргә үлем һәм газапланулар алып килде.

Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «кайнар нокталарда» хәлне җайга салуда контракт нигезендә тик ирекleләр - моның өчен әзерләнгән хәрби хезмәткәрләр генә катнашачак дигән белдерүләренә карамастан, күпсанлы фактлар моның үтәлмәвен раслый. Дагыстандагы хәрби хәрәкәтләрдә Татарстан Республикасының 40 көннән аз гына артыграк хезмәт иткән ике гражданы һәлак булды.

Коралды конфликтлар зонасына әле генә чакырылган солдатларны тиешле хәрби хәзерлексез җибәрүнең акланмаган корбаннарга китерүче гамәлен гаепләп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасыннан 1999 елда чакырылган гражданнарны кайнар нокталардан аларны хәрби частьләре һәм подразделениеләренең даими дислокация урыннарына кайтарылуына кадәр, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарны хәрби хезмәткә алуны туктатып торырга. Төньяк Кавказда һәм башка милләтара һәм территориаль конфликтлар зоналарында Татарстан Республикасы гражданнарының хәрби хезмәт итүенә фәкать ирекле һәм контракт нигезендә генә юл куярга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм Татарстан Республикасы хәрби комиссары әлеге карарның 1 пунктын үтәүне тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы гражданнарының Татарстан Республикасыннан читтә хәрби хезмәт итүен тикшереп тору системасын эшләргә тиешләр.

3. Татарстан Республикасы территориясендә Төньяк Кавказдагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашу өчен запастагы хәрби хезмәткәрләрдән ирекләләр яллауны тыярга.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе, Дагыстан Республикасында хәрби хәрәкәтләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләргә Россия Федерациясе законнары белән Бөек Ватан сугышында катнашучылар өчен билгеләнгән өстенлекле ташламалар, гарантияләр һәм компенсацияләрнең кагылышы мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының иң якын арадагы сессиясе каравына «Кавказ арты, Балтыйк буе һәм Таҗикстан Республикасы дәүләтләре территориясендә хәрби хезмәт узучы, шулай ук гадәттән тыш хәл шартларында һәм коралллы конфликтлар барышында үз бурычларын үтәүче хәрби хезмәткәрләргә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр турында» Россия Федерациясенең 1993 елның 21 гыйнварындагы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча закон чыгару инициативасы хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проектын эшләргә һәм кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2343

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 675. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты - Татарстан Республикасы Хөкүмәте структурасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты - Татарстан Республикасы Хөкүмәте структурасына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Президенты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгын бетерергә.

2.Татарстан Республикасының Матбугат, телерадиотапшырулар эшләре һәм массакүләм коммуникация чаралары министрлыгы булдырырга.

3. Татарстан Республикасының Матбугат, телерадиотапшырулар эшләре һәм массакүләм коммуникация чаралары министрлыгы Татарстан Республикасының бетерелүче Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгының хокуклары варисы, дип билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте структурасы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1996 елның 25 апрелендәге 527 нче, аннан соңгы үзгәрешләре белән, карарына кушымтада «Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасының Матбугат, телерадиотапшырулар эшләре һәм массакүләм коммуникация чаралары министрлыгы» дигән сүзләргә алыштырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты әлеге карарны үтәүне тәэмин итүче, шул исәптән, законнар нигезендә эшкә урнаштыруны тәэмин итү һәм гражданнарның хезмәткә хокукын гамәлгә ашыру гарантияләре өлешендә дә, карарлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2344

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 676. З.Р.Вәлиева кандидатурасын Татарстан Республикасының матбугат, телерадиотап-шырулар эшләре һәм массакүләм коммуникация чаралары министры урынына килештерү турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Президентының Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиеваны Татарстан Республикасының матбугат, телерадиотапшырулар эшләре һәм массакүләм коммуникация чаралары министры урынына билгеләү турындагы тәкъдиме белән килешергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2345

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 677. Татарстан Республикасы халык депутаты З.Р.Вәлиева турында

Татарстан Республикасы халык депутаты З.Р.Вәлиеваның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасының матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министры урынына килештерүгә белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиеваның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатырга.

2. Татарстан Республикасы халык депутаты Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы вазыйфаларыннан азат итәргә.

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумын төзү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның 30 мартындагы, аннан соңгы үзгәрешләре белән, карарыннан түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга:

| | |
|---|---|
| «Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызы | - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары» |

3. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими нигездә эшләүче Татарстан Республикасы халык депутатлары составы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның 26 апрелендәге 54 нче, аннан соңгы үзгәрешләре белән, карарында: «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиева» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2346

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 678. Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте вәкиллекле органнары һәм дәүләт идарәсе органнары хезмәткәрләренең хезмәт хаклары күләмнәрен арттыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте вәкиллек-

ле органнары һәм дәүләт идарәсе органнары хезмәткәрләренең хезмәт хаклары күләмнәрен 2 этапта арттырырга.

2. Татарстан Республикасының республика бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финансланучы Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте вәкиллекле органнары һәм дәүләт идарәсе органнары хезмәткәрләренең хезмәт хаклары күләмнәрен 1999 елның 1 сентябреннән тиешле бюджетлар керемнәре исәбенә 15 процентка арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты:

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте вәкиллекле органнары һәм дәүләт идарәсе органнары хезмәткәрләренең хезмәт хаклары күләмнәрен 1999 елның 1 ноябреннән арттыру һәм моның белән бәйле чыгымнарны финанслау чыганаклары турында тәкъдимнәрне бирергә;

- «Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында» Татарстан Республикасы законы проекты эшләргә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2347

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 679. «Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2348

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 680. "Татарстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Татарстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле турында" Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. "Татарстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле турында" Татарстан Республикасы законы проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2349

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 681. Татарстан Республикасы халык депутаты А.Ә.Камаловны Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими нигездә эшләүдән азат итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы халык депутаты Алмаз Әгъләм улы Камаловны Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими нигездә эшләүдән азат итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими нигездә эшләүче Татарстан Республикасы халык депутатлары составы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1995 елның 26 апрелендәге, аннан соңгы үзгәрешләре белән карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктта түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга:

«Камалов Алмаз - 70 нче Ибраһимов территория сайлауӘгъләм улы округы № 70»

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2350

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 682. Татарстан Республикасы халык депутаты И.Г.Хөснетдиновның «Татарстан Республикасы югары уку йортларын финанслау турында» таләбе хакында

Татарстан Республикасы халык депутаты И.Г.Хөснетдинов таләбе буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы халык депутаты И.Г.Хөснетдиновның «Татарстан Республикасы югары уку йортларын финанслау турында» таләбенә җавапны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 15 сентябре
№ 2351

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 683. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 23 сентябрендәге утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 23 сентябрендәге утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. «Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм рәисләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

2. «Татарстан Республикасы гражданнарының хокук тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

3. «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

4. «16 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның террорлык акты турында күрәләтә ялган хәбәр иткәннәре өчен ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның административ җаваплылыгы хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

5. «Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

6. «Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

7. «Халыкны туберкулездан саклау һәм туберкулезга каршы ярдәм турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

8. «Авыл хуҗалыгы җирләре залогы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

9. «Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча 23 нче Мәскәү сайлау округы округ сайлау комиссиясе составында үзгәреш турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

10. «Татарстан Республикасы халык депутатларының район, шәһәр Советлары халык депутатларының сан составы турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

11. «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны туктатып тору турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 15 сентябрендәге карарын үтәүнең барышы хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

12. «Лицензияләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 23 сентябре
№ 2360

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 684. «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны туктатып тору турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 15 сентябрендәге карарын үтәүнең барышы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны туктатып тору турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 15 сентябрендәге карарын үтәүнең барышы хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х.Мөхәммәтшин мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Россия Федерациясе Президентының 1999 елның 16 сентябрендәге Хәрби хезмәт узу тәртибе турында нигезләмәне раслаган «Хәрби хезмәт узу мәсьәләләре» 1237 нче Указы чыгу, шулай ук Татарстан Республикасы хәрби комиссариатларыннан чакырылган хәрби хезмәткәрләрне Дагыстан Республикасында бурычлар үтәүче хәрби берләшмәләрдән һәм частьләрдән агымдагы елның 1 октябренә кадәр даими дислокация пунктларына кайтару турында Россия Федерациясе оборона министры тарафыннан карар кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны 1999 елның 1 октябреннән яңартырга.

3. «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны туктатып тору турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 15 сентябрендәге карарының 3 пунктын: «, әлеге карарның 1 пунктында каралган очрактан тыш,» дигән сүзләр белән тулыландырырга, «запастагы хәрби хезмәткәрләрдән» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм Татарстан Республикасы Хәрби комиссары Татарстан Республикасы гражданнарының Татарстан Республикасыннан читтә хәрби хезмәт итүләрен даими тикшереп торуны тәэмин итәргә, күрелүче чаралар турында 1999 елның ноябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына хәбәр итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 23 сентябре
№ 2361

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 685. Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм рәисләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Судьялар итеп сайларга:

Казан шәһәренең Вахитов район судына:
Галимова Лилия Галимхан кызын,
Сәхипгәрәев Рәшит Тәлгать улын,
Фәхретдинова Раидә Альберт кызын;

Казан шәһәренең Киров район судына
Солдатова Любовь Алексеевнаны һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Казан шәһәренең Мәскәү район судына
Тихонова Рузалия Мөхәррәм кызын;
Казан шәһәренең Идел буе район судына:
Рахиев Таһир Наил улын,
Садовский Ростислав Игоревичны;

Татарстан Республикасының Әгерҗе район судына
Шакиров Вәзир Шәйхенур улын;

Татарстан Республикасының Азнакай шәһәр судына
Әбдрәшитова Мөсфирә Габдулла кызын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Аксубай район судына
Гыйльманова Нәфисә Миңнехан кызын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Актаныш район судына
Яхин Филүс Локман улын һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Буа район судына:
Садыйкова Дамирә Әхмәт кызын,
Глинкин Леонид Петровичны һәм аны әлеге судның рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Биек Тау район судына
Гасыймов Кадыйр Мөҗип улын;

Татарстан Республикасының Зеленодол шәһәр судына:
Бартенева Венера Мирхәт кызын,

Власюк Виктор Арсентьевичны,
Назыйрова Әлфия Габдулла кызын,
Хөсәенов Марсель Әюп улын;

Татарстан Республикасының Лаеш район судына Фазлыев Фирдәвес Хәнип улын һәм аны әлеге судның рәисе итеп расларга;

Татарстан Республикасының Чаллы шәһәр судына Әхмәтшин Марс Әнәс улын.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**

**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 23 сентябре
№ 2362

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 686. Татарстан Республикасы халык депутатларының район, шәһәр Советлары халык депутатларының санлы составы турында

«Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә һәм халык депутатларының район, шәһәр Советлары һәм тиешле администрацияләрнең башлыклары тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы халык депутатларының район, шәһәр Советлары халык депутатларының санлы составын түбәндәгечә билгеләргә:

| | |
|---|---|
| Азнакай район Советы | 25 |
| Азнакай шәһәр Советы | 25 |
| Аксубай район Советы | 21 |
| Актаныш район Советы | 25 |
| Алабуга район Советы | 10 |
| Алабуга шәһәр Советы | 42 |
| Алексеевск район Советы | 22 |
| Апас район Советы | 23 |
| Арча район Советы | 25 |
| Әгерҗе район Советы | 25 |

| | |
|---|---|
| Әлки район Советы | 25 |
| Әлмәт район Советы | 25 |
| Әлмәт шәһәр Советы | 50 |
| Әтнә район Советы | 15 |
| Балык Бистәсе район Советы | 25 |
| Баулы район Советы | 13 |
| Баулы шәһәр Советы | 17 |
| Балтач район Советы | 25 |
| Биек Тау район Советы | 25 |
| Бөгелмә район Советы | 25 |
| Бөгелмә шәһәр Советы | 50 |
| Буа район Советы | 25 |
| Зәй район Советы | 25 |
| Зәй шәһәр Советы | 25 |
| Зеленодол район Советы | 25 |
| Зеленодол шәһәр Советы | 35 |
| Казан шәһәр Советы | 63 |
| Кайбыч район Советы | 23 |
| Кама Тамагы район Советы | 21 |
| Кукмара район Советы | 25 |
| Лаеш район Советы | 23 |
| Лениногорск район Советы | 20 |
| Лениногорск шәһәр Советы | 45 |
| Мамадыш район Советы | 25 |
| Менделеев район Советы | 21 |
| Минзәлә район Советы | 25 |
| Мөслим район Советы | 25 |
| Нурлат район Советы | 25 |
| Нурлат шәһәр Советы | 35 |
| Питрәч район Советы | 25 |
| Саба район Советы | 25 |
| Сарман район Советы | 20 |
| Спас район Советы | 25 |
| Тәтеш район Советы | 25 |
| Теләче район Советы | 23 |
| Тукай район Советы | 25 |
| Түбән Кама район Советы | 21 |
| Түбән Кама шәһәр Советы | 31 |
| Чаллы шәһәр Советы | 50 |
| Чирмешән район Советы | 22 |
| Чистай район Советы | 25 |
| Чистай шәһәр Советы | 45 |
| Чүпрәле район Советы | 22 |

| | |
|---|---|
| Югары Ослан район Советы | 25 |
| Ютазы район Советы | 25 |
| Яңа Чишмә район Советы | 21 |

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 23 сентябре
№ 2363

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 687. Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча 23 нче Мәскәү сайлау округының округ сайлау комиссиясе составындагы үзгәреш турында

«Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Халык депутатларының Зеленодол берләштерелгән Советы юрисконсульты Дриго Владислав Васильевичны шәхси гаризасы нигезендә Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча 23 нче Мәскәү сайлау округының округ сайлау комиссиясе әгъзасы вазыйфаларыннан азат итәргә.

2. Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча 23 нче Мәскәү сайлау округының округ сайлау комиссиясе әгъзасы итеп Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы каршындагы Дәүләт теркәү палатасының Югары Ослан филиалы директоры Евстафьев Сергей Васильевичны билгеләргә.

3. «Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча округ сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 15 сентябрендәге карарында:

«Дриго Владислав Васильевич - халык депутатларының Зеленодол берләштерелгән Советы юрисконсульты»

дигән сүзләр урынына:

«Евстафьев Сергей Васильевич - Татарстан Республикасы-

ның Юстиция министрлыгы каршындагы Дәүләт теркәү палатасының Югары Ослан филиалы директоры»

дигән сүзләрне язарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 23 сентябре
№ 2364

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 688. «Татарстан Республикасы гражданнарының хокук тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы гражданнарының хокук тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. «Татарстан Республикасы гражданнарының хокук тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында» закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, мөмкин булган эчке юридик каршылыкларын бетерү, статьяларның үзара дөрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен, Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 23 сентябре
№ 2365

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 689. «Наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше һәм аларны куллану белән бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше һәм аларны куллану белән бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дәрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен, Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре, 1
999 елның 23 сентябре
№ 2366

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 690. «Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. «Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе катнашында, ихтимал булган эчке юридик каршылыкларны бетерү, статьяларның үзара дәрес бәйләнешен булдыру, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү өчен, Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы бәйләныш мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре, 1
999 елның 23 сентябре
№ 2367

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 691. «Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, төзәтмәләр рәвешендә бирелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә 1999 елның 23 октябренә кадәр җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе әлеге закон проектын, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 1999 елның 23 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 23 сентябре
№ 2368

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 692. «Авыл хуҗалыгы җирләре залогы турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Авыл хуҗалыгы җирләре залогы турында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм,

әйтелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясенә 1999 елның 23 октябренә кадәр җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясе, кертелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып әлеге закон проектын 1999 елның 23 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 23 сентябре
№ 2369

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 693. «Халыкны туберкулездан саклау һәм туберкулезга каршы ярдәм турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Халыкны туберкулездан саклау һәм туберкулезга каршы ярдәм турында» Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, төзәтмәләр рәвешендә бирелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясенә 1999 елның 23 октябренә кадәр җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре комиссиясе әлеге закон проектын, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 1999 елның 23 ноябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 23 сентябре
№ 2370

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 694. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясе каравына түбәндәге өстәмә мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны билгеләү турында.
2. Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне финанслау турында.
3. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе составын раслау турында.
4. Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасы депутатларын бер мандатлы сайлау округлары буенча сайлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча округ сайлау комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында.
5. «Татарстан Республикасының Законнар җыелмасы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.
6. «Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.
7. «Татарстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.
8. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 8 сентябре
№ 2314

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 695. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясе каравына кертелүче мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче пленар сессиясе каравына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге карарлары проектларын кертергә:

1. Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны билгеләү турында.
2. Татарстан Республикасы халык депутатларын һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне финанслау турында.
3. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе составын раслау турында.
4. Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасы депутатларын бер мандатлы сайлау округлары буенча сайлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча округ сайлау комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында.
5. «Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан билгеләнгән керемгә бердәй салым турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.
6. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.
7. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында.
8. «Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.
9. «Татарстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 8 сентябре
№ 2315

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 696. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы көзге сессиясе чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының көзге сессиясен парламентта даими нигездә эшләүче Татарстан Республикасы халык депутатлары составында 1999 елның 23 сентябрендә Казан шәһәрендә чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 8 сентябре
№ 2317

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 697. 1999 елның 23 сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

1999 елның 23 сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «Татарстан Республикасы гражданнарының хокук тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

2. «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

3. «16 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның террорлык акты турында күрәләтә ялган хәбәр иткәннәре өчен ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның административ җаваплылыгы хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

4. «Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

5. «Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

6. «Халыкны туберкулездан саклау һәм туберкулезга каршы ярдәм турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

7. «Авыл хуҗалыгы җирләре залогы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 8 сентябре
№ 2318

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 698. 1999 елның 23 сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

1999 елның 23 сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге карарлары проектларын кертергә:

1. «Татарстан Республикасы гражданнарының хокук тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

2. «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

3. «16 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның террорлык акты турында күрәләтә ялган хәбәр иткәннәре өчен ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның административ җаваплылыгы хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында.

4. «Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында.

5. «Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында.

6. «Халыкны туберкулездан саклау һәм туберкулезга каршы ярдәм турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшлә-

үне дәвам итү  хакында.

7. «Авыл хуҗалыгы җирләре залогы турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү  хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 8сентябре
№ 2319

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 699. «Суд участоклары һәм мировой судьялар урыннары турында» Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау нәтиҗәләре хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе бәяләмәләрен исәпкә алып, «Суд участоклары һәм мировой судьялар урыннары турында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертмәскә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 8 сентябре
№ 2327

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 700. Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.С.Шәйдуллинның закон чыгару тәкъдиме турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.С.Шәйдуллинның тәкъдимен һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы бәйләнеш мәсьәләләре комиссиясе карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы халык депутаты Ф.С.Шәйдуллинның закон чыгару тәкъдимен Татарстан Респуб-

ликасы Дәүләт Советы каравына кертмәскә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 8 сентябре
№ 2328

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 701. «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе бәяләмәсен исәпкә алып, «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләп бетерүгә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 8 сентябре
№ 2329

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 702. «Татарстан Республикасында риэлтерлык эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе бәяләмәсен исәпкә алып, «Татарстан Республикасында риэлтерлык эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләп бетерүгә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 8 сентябре
№ 2330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 703. «Татарстан Республикасы прокуратурасы турында» Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе бәяләмәсен исәпкә алып, «Татарстан Республикасы прокуратурасы турында» Татарстан Республикасы законы проектын эшләп бетерүгә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 8 сентябре
№ 2331

# III

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 704. Татарстан Республикасы Иминлек советы төзү турында

Гражданлык хокукларын һәм шәхес иреген яклау буенча Татарстан Республикасы Президентының конституциячел вәкаләтләрен тормышка ашыруны тәэмин итү, республика суверенлыгын саклау, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын саклау максатларында һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 111 статьясы һәм «Иминлек турында» Татарстан Республикасы Законының 10,11 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының Иминлек советын төзергә.

**Иминлек советы рәисе**

| | |
|---|---|
| **ШӘЙМИЕВ** Минтимер Шәрип улы | Татарстан Республикасы Президенты |

**Иминлек советы рәисе урынбасарлары:**

| | |
|---|---|
| **МИҢНЕХАНОВ** Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры |
| **МӨХӘММӘТШИН** Фәрид Хәйрулла улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе |

**Иминлек советы секретаре**

**СӘЛИМОВ** Венер Асылгәрәй улы

**Иминлек советы әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| **ӘХМӘТОВ** Марат Готоф улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| **БОГАЧЕВ** Евгений Борисович | Татарстан Республикасы Милли банк рәисе |
| **ВЛАСОВ** Валерий Александрович | Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы эшләре |

| | |
|---|---|
| | һәм гадәттән тыш хәлләр министры |
| **ГӨБӘЙДУЛЛИН** Әгъзам Самат улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе |
| **ГУСЕВ** Александр Петрович | Татарстан Республикасы Дәүләт иминлеге комитеты рәисе |
| **ҖӘЛӘЛОВ** Ринат Гыйният улы | Татарстан Республикасы элемтә министры |
| **ЗЫЯТДИНОВ** | Татарстан Республикасы сәламәтлек Камил Шагар улы саклау министры |
| **ИСХАКОВ** Камил Шамил улы | Казан шәһәр хакимияте башлыгы |
| **КОГОГИН** Сергей Анатольевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы икъти-сад һәм сәнагать министры |
| **МУСИН** Роберт Ринат улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| **НӘФИЕВ** Сәйфихан Хәбибулла улы | Татарстан Республикасы прокуроры |
| **МОСТАЕВ** Рим Шаһали улы | Татарстан Республикасы хәрби комиссары |
| **САЛАБАЕВ** Альберт Михайлович | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| **СӘФӘРОВ** Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы эчке эшләр министры |
| **ХӘМӘДИЕВ** Рәшит Сәет улы | Яр Чаллы шәһәр хакимияте башлыгы |
| **ХӘСӘНОВ** Мансур Хәсән улы | Татарстан Республикасы Фән-нәр академиясе президенты |

2. Татарстан Республикасы Иминлек советы турындагы Нигезләмәне (кушымтада) расларга.

3. Татарстан Республикасы Президентының 1995 елның 17 маендагы «Татарстан Республикасының Президент советын төзү турында» 332 нче указын һәм 1997 елның 29 маендагы «Татарстан Республикасының Президент советы составына үзгәртүләр кертү турында» 271 нче указын көчен югалткан дип исәпләргә.

4. Указ кул куйган көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 13 сентябрь
№ УП-719

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 705. Кадрлар мәсьәләләре буенча җирле хакимият һәм республика дәүләт идарәсе органнарының эшчәнлеген җайга салу хакында

Җирле хакимият һәм республика дәүләт идарәсе органнары тарафыннан килештерелгән кадрлар сәясәтен үткәрү, Татарстан Республикасының җирле хакимиятенә квалификацияле белгечләр туплау, җитәкче вазифасына куела торган таләпләргә туры килмәгән затларны билгеләү очракларын булдырмау, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары системасында башкарма дисциплинаны көчәйтү максатларында **карар бирәм**:

1. Район, шәһәр, шәһәрдәге район хакимият башлыкларына, җирле хакимиятнең структуралы бүлекчәләренә җитәкче билгеләгәнче яки җитәкчене урыныннан азат иткәнче, бу билеләүне (азат итүне) югарыдагы шундый ук республика тармак дәүләт идарә органнары (министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм башка дәүләт идарәсе органнары) булган тиешле республика тармак дәүләт идарәсе органнары җитәкчеләре белән килештерергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына:

тиешле министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм башка республика дәүләт идарәсе органнары турындагы нигезләмәләргә, шушы Указның 1 пунктында күрсәтелгәнчә, җитәкче урынга билгеләүне (азат итүне) әлеге орган җитәкчеләре белән килештерүне исәпкә алган нормаларны кертергә;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты белән берлектә шушы Указның 1 пунктын гамәлгә кертү тәртибен билгеләргә.

3. Указ басылып чыккан көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 14 сентябрь
№ УП-725

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 706. Татар аграр-сәнагать банкын булдыру хакында

Республика агропромышленность комплексын нәтиҗәле финанслау һәм аңа кредит бирүне, икътисадның аграр секторына кредит бирү буенча федераль программаларда катнашуны, Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы производствосына булышлык күрсәтүне оештыру максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасы Милли банкының «Союз» банк группасы һәм «СБС-АГРО» акционерлашкан коммерция банкы, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка хуҗалык җәмгыятьләре катнашында Татар аграр-сәнагать банкын булдыру турындагы тәкъдимнәрен хупларга.

2. Татар аграр-сәнагать банкын булдыру буенча түбәндәге составта Координация советын (алга таба Координация советы) төзергә:

| | |
|---|---|
| ӘХМЄТОВ Марат Готоф улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары-Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, Координация советы җитәкчесе |
| АЙЗАТУЛЛОВ Рафик Расих улы | «СБС-АГРО» акционерлашкан коммерция банкының Татар региональ филиалы директоры |
| БОГАЧЕВ Евгений Борисович | Татарстан Республикасы Милли банкы рәисе |
| КОТЕЛЬНИКОВА Марина Дмитриевна | Татарстан Республикасы Президенты Резерв фондының башкарма директоры |
| МУСИН Роберт Ринат улы | Татарстан Республикасы финанс министры |

3. Координация советына Татар аграр-сәнагать банкын булдыру турында Россия Федерациясе Үзәк банкы, «Союз» банк группасы, «СБС-АГРО» акционерлашкан коммерция банкы, башка

кызыксынган хуҗалык җәмгыятьләре белән сөйләшүләр алып бару максатында тәкъдимнәр әзерләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына:

Татар аграр-сәнагать банкына нигез салу буенча оештыру чаралары уздырырга;

Татарстан Республикасы Президентының Резерв фонды белән берлектә Татар аграр-сәнагать банкы устав капиталына дәүләт (Татарстан Республикасы) өлешен кертү өчен кирәк булган средстволарны, бина һәм башка мөлкәтне дә кертеп, эзләп табарга;

Татар аграр-сәнагать банкының устав капиталына дәүләт өлешен кертер өчен акча бүлеп бирү турында закон проекты эшләп Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә;

Әлеге указны гамәлгә кертерлек башка карарлар кабул итәргә.

5. Татарстан Республикасы район һәм шәһәр хакимияте башлыкларына Татар аграр-сәнагать банкы филиалларының челтәрен оештыру һәм үстерүгә һәръяклап булышлык күрсәтергә, зарурлыкларына карап, аренда шартларында аларга ярашлы биналар бирергә.

«Указ кул куелган көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 14 сентябрь
№ УП-726

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 707. Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына түләүләрнең керүен тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында

Лицензияләштерү турындагы, валюта җайга салуы һәм валюта контроле хакындагы гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертү уңаеннан һәм шулай ук Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына түләүләр буенча бурычларны түләп бетерү һәм агымдагы түләүләрне кертүне тәэмин итү максатында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондын төзү турында» 1996 елның 3 августындагы 475 нче Указына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 3 пункттан «(гаризаларны караган өчен җыемнар һәм лицензия җыемнары)» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

2) 4 пунктның беренче җөмләсендә «алып бетерелмәгән» сүзләре алдына «нигезсез» сүзләрен өстәргә, «180 көн» дигән

сүзләрне «90 көн» дигән сүзләргә алыштырырга, «финанс нәтиҗәләре» дигән сүздән соң «эшчәнлеге» дигән сүзне өстәргә;

3) 4 пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

«Чынлыкта хаклары түләнгән көннән соң 90 көн вакыт узгач импорт буенча алып бетерелмәгән чимал, материал, товар, эшләнгән эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләрнең бәяләре мәҗбүри тәртиптә зыянга чыгарыла һәм импорт белән шөгыльләнүче предприятиеләрнең финанс эшчәнлеге нәтиҗәләренә кертелә. Җибәреп бетерелмәгән импорт продукциясенә (күрсәтелмәгән хезмәтләргә) кагылышлы гамәлдән чыгарылган бурыч суммасы импорт белән шөгыльләнүче предприятиенең салым алына торган керемнәрен киметми. Шул ук вакытта предприятиеләр чынлыкта хаклары түләнгән көннән соң 90 көн вакыт узгач алып бетерелмәгән импорт продукция бәясенең 25 процентын Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына күчерәләр».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Резерв фонды турында Вакытлы нигезләмәне раслау хакында» 1996 елның 13 сентябрендәге 593 нче Указы нигезендә расланган Татарстан Республикасы Президентының Резерв фонды турындагы Вакытлы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) III бүлекнең 7 пунктындагы дүртенче абзацтан «(гаризаларны караган өчен җыемнар һәм лицензия җыемнары)» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

2) III бүлекнең 7 пунктындагы бишенче абзацта «алып бетерелмәгән» сүзләре алдына «нигезсез» сүзләрен өстәргә, «180» көн дигән сүзләрне «90 көн» дигән сүзләр белән алыштырырга;

3) III бүлекнең 7 пунктын бишенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Чынлыкта хаклары түләнгән көннән соң 90 көн вакыт узгач предприятиеләр, оешмалар тарафыннан алып бетерелмәгән импорт продукция (чимал, материаллар, товарлар, эшләнгән эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр) бәясенең 25 проценты»;

алтынчы, җиденче, сигезенче һәм тугызынчы абзацларны - җиденче, сигезенче, тугызынчы һәм унынчы абзацлар дип исәпләргә.

3.Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Милли банкына, Татарстан Республикасы буенча дәүләт салым инспекциясенә, бюджеттан тыш фондларның Татарстан Республикасы Президенты Резерв фондына булган бурычлары тулысы белән түләнеп беткәнчегә кадәр агымдагы түләүләрнең артуын исәпкә алып, алардан Татарстан

Республикасы Президенты Резерв фондына булган бурычларын түләтүне үзгәртеп коруны үткәрергә.

4. Указ басылып чыккан көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан, Кремль
1999 ел, 16 сентябрь
№ УП-742

Искәрмәләр өчен

Искәрмәләр өчен

Искәрмәләр өчен